«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле
гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

| | |
|---|---|
| Килешенде: | Раслыйм: |
| | «Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы» |
| Өлкән тәрбияче | МБМББ житәкчесе |
| ______ Хөснетдинова Д.Р. | ______ Габидуллина Э.С. |
| «31» ___08___ 2022 ел | «31» ___08___ 2022 ел |

# 12 нче мәктәпкә әзерлек (6-7 яшь) төркеменең 2022-2023 нче уку елына эш программасы

Төзеде:
Шайхуллина С.М.
Файзрахманова Э.М.
Миннегулова Л.М.

Яр Чаллы
2022 ел

**Эчтәлек**

1.Максатлар бүлеге.............................................................................................................3
1.1.«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы турында гомуми белешмә.........................................4
1.2. Төркем турында белешмә..................................................................................................4
1.3. Программаның максатлары һәм бурычлары ....................................................................4
1.4. Программага хас үзенчәлекләр ........................................................................................5
1.5. Мәктәпкә хәзерлек төркеме эшчәнлегенең юнәлеше.......................................................8

2.Эчтәлек бүлеге.....................................................................................................................8
2.1.Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары ..........................................................................................8
2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге..........................................................................................................8
2.3 Психологик-педагогик эш эчтәлеге....................................................................................9
2.3.1.«Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе.........................................9
2.3.2.«Танып-белү үсеше» белем бирү өлкәсе……………………...…...…...……26
2.3.3.«Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе……………………………...............37
2.3.4.«Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе……........……...……………...……...49
2.3.5.«Физик үсеш» белем бирү өлкәсе……………………………………...………60
2.4. Ата-аналар белән эш........................................................................................................65

3.Оештыру бүлеге..................................................................................................................68
3.1.Көндәлек режим...............................................................................................................68
3.2. Методик программа белән тәэмин ителеш ......................................................................69
3.3. Предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.......................................................69
3.4. Материаль-техник тәэмин ителеш....................................................................................73

Кушымта
Кушымта 1. Балаларның яшь үзенчәлекләре ......................................................................74
Кушымта 2. Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы............................................................76
Кушымта 3. Белем бирү эшчәнлеге челтәре .......................................................................77
Кушымта 4. Сәламәтләндерү чаралары ..............................................................................78
Кушымта 5. Милли–җирле компонент (ЭРС, УМК) ...........................................................81

## 1. Максатлар бүлеге

Бу программа ФДББСна нигезләнеп эшләнгән Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге «Туганнан алып мәктәпкәчә» төп белем бирү программасына һәм балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасынатаянып төзелде.

**Эш программасытүбәндәге норматив документларгатаяныптөзелде:**

1. Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»с изменениями и дополнениями от 14.07.2022 №298, №299, №300
2. Федеральный закон от 03.08.2018 №317-ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации»;
3. Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России, Департамента общего образования от 28.02.2014 г. №08-249;
4. Профессиональным стандартом "Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального, основного и среднего общего образования) (воспитатель, учитель)", утвержденного приказом Минтруда и Соцзащиты РФ № 544н от 18 октября 2013 г. (с изм. на 5.08.2016г);
5. СанПиН 2.4.3648-20 от 28 сентября 2020 г «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодёжи»;
6. СанПиН 2.3/2.4.3590-20 "Санитарно-эпидемиологические требования к организации общественного питания населения" от 27 октября 2020 г. № 32;
7. СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания» от 28.01.2021 № 2;
8. Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социальной инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой короновирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 30 июня 2020 года №16.
9. Приказ Министерства просвещения РФ от 31.08.2020г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления деятельности по ООП – образовательным программам ДО»;
10. Методическими рекомендациями Минобрнауки «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248;
11. Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» от 08.07.1992 №1560-XII (изменения и дополнения от 27.04.2017 г. №27-ЗРТ);
12. Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013 г. №68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г.);
13. Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей № 49 «Гульназ», постановление от 22 сентября 2017 г. № 5633;
14. Примерная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой, 2020 г.
15. «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 49 «Гульназ», приказ № 192 от 31 августа 2020 года.

## 1.1.Гомуми белешмә

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**
«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.
**Кыскача атамасы:** «Гөлназ» 49нчы балалар бакчасы МБМББУ.
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**
*субъект РФ:* Татарстан Республикасы
*индекс*: 423828
*торак пункты:* Яр Чаллы шәһәре
*урам: Шамил Усманов*
*йорт: 133*
*шәһәрнең федераль телефон коды:* (8552) *телефон:* 42-65-92
*факс:* 42-65-92 *e-mail*: det.sad49@mail.ru
сайт: https://edu.tatar.ru/n_chelny/page92698.htm
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**
Габидуллина Эльза Сагил кызы
**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**
1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы...)
3.Сәламәтләндерү һәм авырулардан профилактика чаралары.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.00-18.00 сәгатькә кадәр эшли.

## 1.2. Төркем турында белешмә
### Төркемнең составы

| № гр | яше | Саны | Малайлар | Кызлар |
|---|---|---|---|---|
| 12 | 6-7 | 13 | 5 | 8 |

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем бирү стандартларына (ФДББС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек алып бару. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. «Татарстан Республикасы халыклары телләре» турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен камиллләштерүне дәвам итү.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

## 1.3 Программаның төп максатлары һәм бурычлары

**Программаның төп максатлары**-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәгетормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү. Программада баланың шәхесен үстерүгә, балалоарның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук

мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын баба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә. Бу максатлар бала эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, аралашу, хезмәт, танып-белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында тормышка ашырыла.

**Бурычлар:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә ия:

- һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;
- төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергәярдәм итәрлек кешелеклде һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;
- тәрбия-белембирүпроцессыниҗадиоештыру;
- белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;
- балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;
- мәктәпкәчә белеем бирү учреждениесеһәмгаиләшартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;
- балалар бакчасы һәм башлавнгыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү;
- региональякынкилүнегамәлгәашыру.

## 1.4 Программага хас үзенчәлекләр

***Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек***

Программаның өстенлеге — ирекле, үз-үзенә ышанган, актив тормыш позициясенә ия, тормыштагы төрле хәлләрдән чыгу юлларын табуга иҗади килергә омтылган, үз фикере булган һәм аны яклый белә торган кеше тәрбияләү.

***Программаның патриотик юнәлгәнлеге***

Программада балаларда Туган илгә карата мәхәббәт, патриотик хисләр, Ватанның казанышлары белән горурлану, Россиянең героик үткәне һәм бәхетле киләчәге булган күпмилләтле бөек ил икәнлегенә ышаныч тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

***Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек***

Ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам, кечкенәләргә, олы яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт кебек традицион кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү; традицион гендер күзаллаулары булдыру; балаларның үз гамәлләрендә уңай үрнәккә иярү омтылышын тәрбияләү. Алга таба укуны дәвам итү максатын кую Программа балаларда танып белү кызыксынучанлыгын үстерүгә, белем алу омтылышына, алга таба бөтен тормышы буена укуга (мәктәптә, институтта һ.б.) карата уңай мотивациягә; барлык кешеләргә дә белем алырга кирәклекне аңлауга юнәлтелгән. Белем алуга карата аны иң мөһим тормыш кыйммәтләренең берсе итеп карауны формалаштыру.

***Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек***

Программа тәрбиячеләр алдына куя торган төп бурычларның берсе — балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру, уңай гадәтләр, шул исәптән дөрес туклану гадәте, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү.

***Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек***

Программа һәрбер баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән, аңа исә тормыш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрендә дә (көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайту һ.б.), бала белән үзара аралашу формаларында һәм ысулларында да (аның индивидуальлегенә карата хөрмәт, эмоциональ халәтләренә игътибарлылык, үз-үзенә ихтирамлылык хисләрен яклау һ.б. ш.) балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу хисабына ирешелә.

***Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән үзара бәйләнеш***

Программа гаиләнең уникаль тәрбия институты буларак кыйммәтен һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тыгыз мөнәсәбәтләр булдыру кирәклеген ассызыклый. «Балалар бакчасының гаилә белән бәйләнешы» бүлегендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән төп эшләү формалары тасвирлана, аларны куллану педагогларга мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми мәгариф программасын уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Бала белән өйдә шөгыльләнү өчен кулланмалар — «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән китаплар белән тәэмин ителү Программаның мөһим өстенлеге булып тора.

**Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**
**Максат ориентирлары**

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя. Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

**Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы**

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз

яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы. Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята.

Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел, табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан.

Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата- аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

## Педагогик диагностика

Программаны гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кысаларында уздырыла. Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);
• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.

Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:

1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);

2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү. Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

### 1.5 Мәктәпкә әзерлек төркеме эшчәнлегенең юнәлеше

Төркемдә белем бирү процессы комплексла һәм яңа парциаль программалар кулланылып үткәрелә:

Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан алып мәктәпкәчә”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү комплексла программасы.

Программа сөйләм телен үстерү бүлегеннән тыш тулы күләмдә кулланыла.

*<u>Парциаль программа:</u>*

Р.К.Шаехова. “Сөенеч - Радость познания” региональ мәктәпкәчә белем бирү программасы, (ФДБС туры китерелгән);

## 2. Эчтәлек бүлеге

### 2.1. Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның сыйфатлы физик үсешен тәэмин итү. Һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Үз вакытында гомуми хәрәкәтләр һәм кул хәрәкәтләре формалашуга, шуышырга һәм йөрергә өйрәнүгә ярдәм итү.

Баланың талчыгуын булдырмау.

Күрү һәм ишетү юнәлешләрен формалаштыру.

Сиземләү тәҗрибәсен баету.

Өлкән кешенең сүзләрен аңлау сәләтен үстерү һәм актив сөйләмгә ирешүгә әзерләү.

Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү процессына керешү омтылышларын хуплау.

Балаларның үзара татулыгына, якын кешеләренә карата аерым дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

Уенчыкларга, рәсемнәргә, музыкага, җырлауга карата кызыксыну уяту; баланың гади бию хәрәкәтләре башкарудагы активлыгына булышлык итү.

Һәр баланың үз яшенә туры килгән сәләтләрне үзләштерүенә актив ярдәм итү, алынган нәтиҗәләрне системалы рәвештә һәм дөрес анализлау.

### 2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге

2–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати- эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала.

## 2.3 Белем өлкәләре буенча комплеклы - тематик план
## 2.3.1. «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

### *Социальләштерү*
### *Аңлатма язуы*

*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* **белем бирү бурычларын** *билгели.*

Балалар бакчасында балаларның (кечкенәләр, үзеннән зурраклар, яшьтәшләре, малайлар-кызлар, төркемгә килгән «яңа» балалар белән) туган телдә аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

Төрле эшчәнлек төрләрендә балаларга туган телдә үзара һәм өлкәннәр белән бай, эчтәлекле аралашу өчен шартлар тудыру.

Элементар әхлак кагыйдәләренә өйрәтү, әхлак буенча аралашу үрнәкләре бирү, сөйләмдә татар халык фольклорын (мәкальләр, әйтемнәр, юаткычлар һ. б.) куллануга теләк уяту.

Бөтен кешелек өчен уртак байлык булган патриотизм хисләренең әхлакый нигезен булдыру өчен шартлар тудыру (гаиләсенә, балалар бакчасына, туган ягына, иленә, әйләнә- тирә дөгел әргә мәхәббәт).

Гаиләң һәм аның тарихы турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай, абый-эне, апа-сеңел, туганнан туган абый-апалар), гаиләдәге урыны, туганлык җепләре һәм гаилә эчендә бәйләнешләр («Мин әтигә – ул, ә әбигә – онык», «Газизә апа – минем Фатыйма әбиемнең кызы»), әти-өниләрнең һәм туганнарның һөнәр һәм шөгыльләре турында күзаллаулар булдыру; туганнарның фотографияләрен карап, баланың әти-әниләре һәм башка туганнары белән тышкы охшашлыгына басым ясау.

Үзенең уңыш һәм казанышларына, әти-әниләренең, якын кешеләренең, дусларының, Олимпия уеннары спортчыларының, артистларның халыкара конкурсларда яулаган уңыш һәм казанышларына шатлык, горурлык хисләре тәрбияләү.

Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелеген хуплау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган белемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.

Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кулдан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта булган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын, мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк режиссерлык уеннарына булышлык күрсәтү.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау, Идел буе, халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, әти-әниләр һәм кунаклар алдында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.

Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәүне, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.

Белем өлкәсе “Социаль- шәхси үсеш” җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.

Планлаштыруинтеграция принциплары, төрле хезмәт  һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре  формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

***Сюжетлы – рольле уеннар***
***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Эшчәнлек эчтәлеге** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|---|
| | I | Балалар бакчасы | Тәрбияче балаларны кабул итә,иртәнге гимнастика үткәрә, балаларны ашата, алар белән уйный. | |
| | II | Транспорт | Гаражда күптөрле эшләр өчен машиналар тора..Машина йөртүчеләр праваларын алалар, диспетчер эш бирә, бензин салалар,биремне үтиләр: автобус пассажирлар, ашыгыч ярдәм машинасы доторны чирлеләр яныны йөртә , экскурсия автобуслары йөри һ.б. | |
| | III | Шәһәр буйлап сәяхәт | Башка шәһәрдән экскурсиягә ял итүчеләр килгән. Экскурсовод аларга шәһәрне төрле урыннарын күрсәтә,<br>сөйли. | |
| | IV | Кибет | Ашамлыклар кибетендә төрле отделлар бар – күп сатучылар эшли, кассалар күп. Сатып алучыларашамлыкларны карыйлар, сайлыйлар, сатып алалар. | |
| октябрь | I | Транспорт | Урамнарда күптөрле эшләр өчен машиналарйөриләр. Җәяүлеләр тротуардан йөриләр. Машиналар һәм җәяүлеләр юл йөрү кагыйдәләрен бозмыйлар. Машиналар махсус машиналарга юл бирәләр(ашагыч ярдәм, янгын сүндерүче һ.б.). | |
| | II | Балалар бакчасы | Тәрбияче иртәнге гимнастика үткәрә, балалар җыр шөгыленә киләләр-җырлыйлар, бииләр; уйныйлар | |
| | III | Уенчыклар кибете | Сатып алучылар уенчыклар сайлыйлар, сатучы белән киңәшләшәләр,кассага акча түлиләр,чекларын сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучыларелән ягымлы сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә, аларның ни өчен яхшы булуы турында сөйли, уенчыкларны биреп җибәрә, сатып алынган әйберләр өчен рәхмәт әйтә. | |
| | IV | Почта | Кешеләр бер- берсенә хатлар язалар, телеграммалар, посылкалар җибәрәләр. Хат ташучы почтаны адреслар буенча тарата. | |
| ноя брь | I | Шифаханә | Табиб кешеләрне дәвалый: тыңлый, кан басымын үлчи, тамагын карый, рецепт язып бирә. Шәфкать туташы укол ясый, бәйли. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | Төзүчеләр | Төзүчеләр зур гараж җиткерәләр, анда күп машиналар торачаклар. | |
| | III | Т ранспорт | Йөк һәм җиңел автомашиналар урам буйлап баралар, җәяүлеләр тротуар буйлап баралар, юл аша чыгалар , бар да юл кагыйдәләрен саклап йөриләр. | |
| | IV | Кибет | Төрле бүлеклә белән яңа супермаркет ачылган:савыт- саба, җиһаз, канцтоварлар һәм башкалар. Сатып алучылар товар сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар (төсе, материалы, әһәмияте) | |
| декабрь | I | Җәнлекләр шифаханәсе | Кешеләр шифаханәгә киләләр һәм авыру җәнлекләрне алып киләләр. Ветеринар авыру җәнлекләрне дәвалый: карый, җылыткыч куя, дарулар билгели, уколлар ясый. | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | II | Гаилә | Яңа ел бәйрәме: чыршы сатып алу һәм аны бизәү, гаилә әгъзаларына бүләк әзерләү, котлаулар һәм бүләкләр белән Кыш бабайның килүе. | |
| | III | Кыш бабайныңостаханәсе | Кыш бабай чыршы бизәү очен уенчыклар әзерләү остаханәсе ачуны сорап хат җибәргән. Кабул итүче килүчеләрдән заказлар ала һәм уенчыклар ясарга бирем бирә. Осталар төрле материалдан уенчыклар ясыйлар. Кабул итүче үтәлгән заказларны бирә. | |
| | IV | Китапханә | Укучылар китапханәгә киләләр. Алар стендлар карыйлар,китаплар сайлыйлар. Китапханәче кирәкле китапларны бирә, аларны укучылар формулярына язып куя. | |
| январь | I | Балалар бакчасы | Балалар бакчасында Яңа ел бәйрәме: балалар уенчыклар ясыйлар, чыршы бизиләр, Кыш бабай белән Кар кызы киләләр, балалар Яңа ел бәйрәме һәм кыш турында шигырьләр сөйлиләр, күңелле уеннар уйнылар. | |
| | II | Чәчтараш | Чәчтарашка әниләр балалары белән киләләр. Ирләр һәм хатын- кызлар залы эшли. Осталар чәч кисәләр, кырындыралар, баш юалар, клиентларның чәчләрен тарыйлар. Алар игътибарлы һәм ягымлылар. | |
| февраль | I | Хәрби уеннар | Уеннарда төрле гаскәр төрләре катнашалар гдиэгезчеләр, җәяүле гаскәр, танкистлар, очучылар.Алар командирларның әмере буенча төрле йөкләмәләр үтиләр. Хәрби уеннардан соң концерт оештыралар: җырлар җырлыйлар,бииләр. | |
| | II | Ашыгыч ярдәм | Чакырту буенча врачкилә,беренче ярдәм күрсәтә: укол ясый, тамагын карый, температурасын үлчи, рецепт язып бирә. | |
| | III | Театр төзү | Төзүчеләр театр төзиләр. Кассир билетлар сата. Тамашачылар аларны сатып | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | алалар һәм тамашалар залына үтәләр. Аларны билет тикшерүче үткәрә. Билет тикшерүче тамашачыларга программка тәкъдим итә. Артистлар спектакльне кабатлыйлар һәм тамашачыларга күрсәтәләр. | |
| | IV | Янгын сүндерүчеләр өйрәнүләрдә | Янгын сүндерүчеләр янгын сүндерергә ашыгалар: янгын сүндерү машинасына тиз итеп утыралар, янгын урынында янгын сүндерү җиңен сүтәләр, янган өйдән кешеләрне коткаралар, йорт хайваннарын алып чыгарга ярдәм итәләр. Янгын сүндерүчеләр баскыч, носилка кулланалар.кешеләрне коткаралар, йорт хайваннарын алып чыгарга ярдәм итләр. Янгын сүндерүчеләр баскыч, носилка кулланалар. | |
| март | I | Балалар бакчасы | Тәрбияче балаларны кабул итә, иртәнге гимнастика үткәрә, балаларны ашата, алар белән уйный | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү,балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| | II | Транспорт | Йөк һәм җиңел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бетенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр. Шофер машина йөртергә хокук таныклыгы ала , машина га бензин сала , юлга чыгарга путевка ала. | |
| | III | Шәһәр буенча экскурсия | Туристлар икенче шәһәрдән экскурсиягә килгәннәр. Экскурсовод шәһәр белән таныштыра. | |
| | IV | Магазин | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре һ.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар ( төсе, материалы, кулланылышы). | |
| апрель | I | Җәнлекләр шифаханәсе | Кешеләр шифаханәгә авыру җәнлекләрне алып киләләр. Ветеринар җәнлекләрне карый, градусник куя, дару бирә, уколлар ясый | |
| | II | Аптека | Дарулар сатучы рецеп буенча дарулар бирә. | |
| | III | Уенчыклар кибете | Сатып алучылар уенчык сайлыйлар, сатучы белән киңәшәләр, кассага акча түлиләр, чекларны сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән әдәпле итеп сөйләшә, апарга төрле уенчыклар тәкъдим итә, аларның ни өчен яхшы булуын сөйли, уенчыкны бирә, сатып алучыга рәхмәт әйтә. | |
| | IV | Почта | Кешеләр бер-берсенә хатлар язалар, телеграмма, посылка җибәрәләр. Почта | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ташучы аларны адреслар буенча тапшыра. | |
| май | I | Шифаханә | Терапевт кешеләрне дәвалый: тыңлый, баскалап карый, кан басымын үлчи, тамак төбен карый, рецепт яза. Шәфкать туташы укол ясый, яраларны бәйли | |
| | II | Хәрби уеннар | Уеннарда төрле гаскар төрләре катнашалар: диңгезчеләр, җәяүле гаскәр, танкистлар, очучылар. Алар командир әмере буенча төрле йөкләмәләр үтиләр. Хәрби уеннардан соң концерт оештыралар: җырлар җырлыйлар, бииләр. | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен ныгыту, һөнәрләрнең кирәк-яраклары турындагы белемнәрен үстерү, диалог корып сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | Транспорт | Йөк һәм җидел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бетенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр. | |
| | IV | Магазин | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре һ.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар (төсе, материалы, кулланылышы). | |

## *Хезмәт*

### *Аңлатма язуы*

«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә ***һәм белем бирү бурычларын*** билгели.

Татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз», «һөнәрле үлмәс» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын әкияттә хезмәт итүче геройларга юнәлдерү. Балаларның эш барышларын Г. Тукай шигырьләрендәге («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ. б.) юллар белән бәйләү.

Туган шәһәрдәге (авылдагы) укытучы, нефтьче, сыер савучы һ. б. һөнәр ияләре турында күзаллауларын формалаштыру.

Балалар бакчасы участогында тәрбияче белән эшләгәндә, балаларның актив катнашуын булдыру: яфраклар коелгач, кулларыннан килгәнчә участокны җыештыру, шәһәрдә яшәүче кошларга өстәмә азык бирү.

Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгәндә, өлкәннәргә кулларыннан килгәнчә булышу, өйдә үз вазифаларын үтәүгә тарту.

### *Комплекслы-тематик план*

| **Тема** | **Интеграция** |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |

| | |
|---|---|
| 1. Табын әзерләү, ашау әйберләрен дөрес кую- кашык һәм пычакны – тәлинкәнең уң ягына,чәнечкене – сул ягына кую, ашаганнан соң савыт-сабаны өсәлдән җыеп алу күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Шөгыль өчен тәрбияче әзерләгән материалларны таратып чыгу (Нәфасәти шөгыльләр өчен материалны аерым өстәлгә тезеп кую), иптәшләренә шөгыль өчен материал әзерләргә ярдәм итүкүнекмәләрен ныгыту.<br>3. Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын юып-сөртеп торырга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә, курчак киемнәрен юарга, чишенү шкафларын тәртиптә тотарга, төркемдәге урындыкларны юарга, сөлгеләр шкафын сөртергә,физзалда тупларны, гимнастик таякларны юарга,нәниләрнең китапларын рәтләргә өйрәтү | *Уку:* профессияләр турында хикәяләр уку, шофёр профессиясе буенча рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* балалар бакчасынба азык – төлек алып килүче машиналарны күзәтү, күргәннәр буенча әңгәмә оештыру. |
| ***Октябрь*** | |
| 1. Салфетканы кисеп куярга, өстәлдән калган ризыкны селереп алырга; математика өчен материалны таратырга: линейка, конвертлар, таратма материалларны; шөгыльдән соң бар материалны җыяргаөйрәтү.<br>2. Уенчыклар шкафын җыештыру, өстәл уеннарының тышларын рәтләү, бизәү әйберләре, бәйрәмнәргә костюмнар әзерләүдә катнашу.<br>3. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Һәр көн саен юыну һәм тешләрен чистарту,ашау алдыннан һәм пычранган саенкулларын юу күнекмәләре бирү.Билгеле бер эзлеклелектә киенә һәм чишенә, киемне дөрес һәм пөхтә итеп шкафка, аяк киемен үз урынына куя, дымланган киемнәрне вакытында киптерә, аяк киемнәренкарап-чистартып (юу, сөртү, ялтырату) торырга гадәтләндерү.Үзендәге җыйнаксызлыкны күреп, тәртипкә китерергә, иптәшенә аның өс-баш һәм аяк киемендәге төгәлсезлекне әдәпле итеп кенә искәртергә, ал арны бетерүдә булышлык итәргә өйрәтү. Үзара ярдәмләшү тойгысы тәрбияләү.<br>4. Табын әзерләү, икенче һәм өченче (җиләк-җимеш) ризыкларны тарату, ашаганнан соң савыт-сабаны җыеп алу, идән себерү кебек дежурлык бурычларын мөстәкыйль һәм намус белән башкарырга. | *Сәламәтлек:* үз – үзеңне тәртиптә тотарга кызыксындыру, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>*Куркынычсызлык:* хезмәт кирәк–яракларыннан дөрес куллану һәм аларны дөрес урнаштыру күнекмәләрен фолмалаштиыру. |
| ***Ноябрь*** | |

| | |
|---|---|
| 1. Табигать почмагындата дежур тору: үсемлекләргә су сибү, кипкән яфракларын алу, һава торышыкалендарен алып бару.Өстәлне пөхтә итеп җыештыру, ашамлык валчыкларынщетка белән себереп алу күнекмәләренныгыту.<br>2. Ябыштыру шөгыленнән соң өстәлдән кәгазь кисәкләрен җыеп алырга күнектерү.<br>3. Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкныһәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын юы- сөртеп торырга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә өйрәтү.Балалар бакчасы мәйданчыгында мөстәкыйль рәвештә җыештыру эшләре үткәрергә: юлларны себереп, чүп-чардан, кардан чистартырга.<br>4. Йокыдан торгач, урын-җирне мөстәкыйль җыештырырга күнектерү. | *Уку:* повар профессиияәсе турында хикәяләр уку, рәсемнәр карау.<br>*Аралашу:* балалар бакчасы кухнясына экскурсия, повар эшен күзәткәннән соң, хикәя төзергә өйрәтү.<br>*Социальләштерү:* кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру . |
| ***Декабрь*** | |
| 1. Табынны тиз һәм пөхтә җәя һәм җыя белү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Шкафтан шөгыльгә кирәкле материалны алырга, махсус өстәлгә урнаштырыга, иптәшләренә аларны шөгыльгә әзерләргә, шөгыльдән соң җыеп куярга ярдәм итү, нәфасәти шөгыльләрдән соң өстәлләрне сөртергә.<br>3. Үсемлекләрне коендырырга, ашар өчен яшеллеккә суган утыртырга өйрәтү.<br>4. Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын юып-сөртеп торырга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә,курчак киемнәрен юарга, чишен шкафларын тәртиптә тотарга, төркемдәге урындыкларны юарга, сөлгеләр шкафы сөртергә,физзалда тупларны, гимнастик таякларны юарга, нәниләрнең китаплары рәтләргә өйрәтү.<br>5. Уен мәйданчыгын җыештыру: себерү,чүп җыю, веранда җыештыру, уен мәйданчыгынкардан чистарту, Карныоешыр өчен һәм корылмалар төзер өчен өемнәргә җыярга, корылмаларны кардан чистартырга.. Яшелчә һәм чәчәк түтәлләренә кар ташырга.Куакларны, агачларның аскы өлешләренкар белән капларга. | *Социальләштерү:* балаларны шәхси һәм тәркемләп кушылган эшләрне үтәргә тарту, бер–берсе арасында тәрбияче ярдәме белән эшне бүлергә өйрәтү.<br>*Уку:* зурлар хезмәтенең киршклеге турында хикәяләр уку, зурлар хезмәтен хөрмәт итү турында үрнәк китерү.<br>*Аралашу:* хезмәтнең җәмгыять, гаилә һәм балалар бакчасы өчен кирәклеге турында сөйләшү. |

| **Январь** | |
|---|---|
| 1. Шөгыльләргә эш урынының әзерлеген’ күзәтергә, балаларның эш урынын шөгыльгә җитмәгән материал белән тулыландырырга.Җыр шөгыльләренә әйбер әзерләүдә катнашырга.<br>2. Уен почмакларын тәртипкә китерү; төзү материалларын, өстәл уеннарын, хезмәт өчен материалны һәм эш коралларын урынына алып куярга.<br>3. Шөгыльгә киткәндә, урамга чыкканда бар да тәртиптә калуын тикшерү: шкафлардагы,урындыклардагыкиемнәрнең төрелү тәртибен, балалар җыештырганнан соң караватлар тәртибен карау.<br>4. Курчакларны тәртипкә китерергә: юарга, чәчләрен тарарга, кирәк булса киемнәрен алыштырырга.Өзелгән сәдәфләрен тегәргә.Төзәтелергә тиешле уенчыкларны, китапларны, тартмаларны сайларга.<br>5. Кардан корылмалар, кечкенәләр өчен тау ясаудакатнашу. Юлларга ком сибү. | *Социальләштерү:* башланган эшне азагына кадәр эшләүне тәрбияләү, аны яхшы эшләүне булдыру.<br>*Аралашу:* врач хезмәте буенча сөйләшү, рәсемнәр карау, теманы тикшерү теләге уяту. |
| **Февраль** | |
| 1. Ябыштыру шөгыле өчен кәгазь хәзерлек әзерләргә, физкультура шөгыле өчен җиһазлар әзерләүдә һәм урнаштыруда катнашу, шөгыльдән соң эш урыннарынтәртипкә китерергә.<br>2.Тартмага ашар өчен яшеллеккә суган утыртырга.<br>3. Кыш турында йомгаклау әңгәмәсе өчен һава торышы календаре әзерләү.<br>4. Тере почмакта дежур тору бурычларын мөстәкыйль һәм җаваплылык тоеп башкарырга: бүлмә гөлләренә су сибәргә, туфракны йомшартырга, җимлекләрне юарга, азыкны әзерләп (юып, кискәләп) бирергә өйрәтү. Тере почмактагы тереклекияләре һәм үсемлекләр турында мөстәкыйль кайгыртырга гадәтләндерү.<br>5.Төзәтелергә тиешле уенчыкларны, китапларны, тартмаларны сайларга.<br>6. Уенчыкларны һәм төзү материалларын юарга, сөртергә.<br>7. Билгеле бер тәртиптә урындакларны тезәргә. | *Куркынычсызлык:* карны күрәгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне формалаштыру.<br>*Таныл белү:* табигатьпочмагындагы гөлләрнең һәм усемлекләрнеңисемнәрен белү. |
| **Март** | |

| | |
|---|---|
| 1. Табынны тиз һәм пөхтә җәя һәм җыя белү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Шкафтан шөгыльгә кирәкле материалны алырга, махсус өстәлгә урнаштырыга, иптәшләренә аларны шөгыльгә әзерләргә, шөгыльдән соң җыеп куярга ярдәм итү, нәфасәти шөгыльләрдән соң өстәлләрне сөртергәкүнектерү.<br>3. Үсемлекләрне коендырырга, ашар өчен яшеллеккә суган утыртырга.<br>4. Уен почмакларын тәртипкә китерү; төзү материалларын, өстәл уеннарын, хезмәт өчен материалны һәм эш коралларын урынына алып куярга.<br>5. Шөгыльгә киткәндә , урамга чыкканда бар да тәртиптә калуын тикшерү:шкафлардагы, урындыклардагы киемнәрнең төрелү тәртибен, балалар җыештырганнан соң караватлар тәртибен.<br>6. Уен мәйданчыгын, веранданы, чистартырга.Тәрбиячегә кар таратырга ярдәм итү. | *Аралашу:* йорт хайваннарын караучы хезмәте турында сөйләшү. |
| ***Апрель*** | |
| 1. Шөгыльләргә эш урынының әзерлеген күзәтергә, балаларның эш урынын шөгыльгә җитмәгән материал белән тулыландырырга.<br>2. Җыр шөгыльләренә әйбер әзерләүдә катнашырга.<br>3. Кошларга яшел ашамлык өчен ашлык бөртекләре чәчәргә өйрәтү. Күзәтү өчен кузаклы үсемлекләр утырту.<br>4. Уенчыклар шкафын җыештыру, өстәл уеннарының тышларын рәтләү, бизәү әйберләре, бәйрәмнәргә костюмнар әзерләүдә катнашу. | *Уку:* С. Михалков«Почта», 1 өзеген ятлау.<br>*Аралашу:* балаларга почтальон (хат ташучы) хезмәте турында сөйләү. |
| ***Май*** | |
| 1.Ябыштыру шөгыле өчен кәгазь хәзерлек әзерләргә, физкультура шөгыле өчен җиһазлар әзерләүдә һәм урнаштыруда катнашу, шөгыльдән соң эш урыннарынтәртипкә китерергә<br>2. Төркем бүлмәсендә үстерелгән чәчәкләрне чәчәк түтәленә күчереп утыртуда катнашу.<br>3. Тәрбияче кушуы буенча алып чыгу өчен материалны һәм уенчыкларны сайлап алып урамга алып чыгарга. Керер алдыннан уенчыкларны җыярга һәм аларны тәртипкә китерергә.Уен мәйданчыгын, веранданы җыештыру. | *Аралашу:* үсемлекләрнең үсешен күзәтү, күргәннәр буенча сөйләшү.<br>*Социальләштерү:* уеннарда рольләрне дөрес башкаруны ныгыту. |

***Куркынычсызлык***

***Аңлатма язуы***

*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру***

Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык хисе үстерү; тормыш һәм сәламәтлекләрен саклау өчен, үз-үзеңне дөрес тотуның әһәмиятен аңлауларына ирешү.

Таныш булмаган кешеләр белән мөмкин булган һәм очраклы очрашулар һәм аралашу барышында балаларда үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында ачык күзаллау булдыру. Таныш булмаган кеше белән үзең генә калу һич тә ярамавына һәм куркынычлыгына игътибарларын юнәлтеп, балалар белән шундый очраклы очрашулар вакытында килеп чыккан хәлләрне бергәләп карау һәм фикер алышу.

Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру

Хәрәкәт юнәлешен (сүзле яки җаваплы) сигнал буенча алыштырып, «үзеңнән» һәм «үзеңә таба», бирелгән юнәлештә хәрәкәт итү; бер урыннан икенче урынга мөмкин булган күчешләр турында килешеп, әйләнә-тирәне үзләштерү; уен барышында объекттан (хәрәкәт итүче машина, поезд) хәрәкәт чагыштырмалылыгын билгеләргә өйрәтү.

Әйләнә-тирәдәге предметларның бер-берсенә карата булган урыннарын мөстәкыйль ачыклый белүләренә ирешү: өстенә – өстендә, буенча – астында, сулда – уңда, артында – алдында, янында, янәшәсендә, арасында, уртасында, өстәрәк – астарак. Тирә-юньдәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең торган урыныңны билгеләү күнекмәләре үстерү.

Светофорның төсләрен (ике яклы, җәяүле өчен), «Балалар», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләрнең хәрәкәте тыела», «Велосипедлар хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы», «Хастаханә» һ. б. юл хәрәкәте билгеләренең зурлыгын, төсен һәм формасын, регулировщик таягының төсен ачыклау нигезендә, сенсор сиземләү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларга югары куркынычлык зоналары турында сөйләү. «Тайгак юл», «Куркыныч борылыш», «Юл эшләре», «Кыргый хайваннар», «Шлагбаумлы тимер юл чаты» һ. б. кисәтүче юл билгеләре белән таныштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү.

Балаларны берничә полосалы хәрәкәт булган юлны чыгу алгоритмы белән таныштыру; юлларда, юл аркылы чыкканда, тәртипкә салына торган урам чатларын чыкканда ориентлашырга күнектерү. Балаларны «юл билгесе» төшенчәсе, юл чатларында җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган «Җәяүлеләрнең җир асты юлы», «Җәяүлеләрнең җир өсте юлы» билгеләре белән таныштыру.

Хәрәкәтне сигналлар ярдәмендә җайга салучы ЮХИДИ инспекторы эшчәнлеге белән таныштыру, җәмгыять өчен аның хезмәтенең әһәмиятлелеген бәяләү күнекмәләре үстерү.

Балаларның махсус транспорт чаралары билгеләнеше («ашыгыч ярдәм» машинасы, «полиция» машинасы, «янгын сүндерү» машинасы һ. б.) турындагы белемнәрен ачыклау; сигнал тавышларына игътибар итәргә, аларны аера белергә өйрәтү; кайбер аерым очракларда махсус транспорт чараларының юл йөрү кагыйдәләрен бозу мөмкинлегенә игътибар иттерү.

Метрода: вагонда (ишекләргә сөялмәү, чыгарга алдан әзерләнү), станциядә (бер юнәлештә хәрәкәт итү, тыелган сызыкка басмау), эскалаторда (уң якта басу, үз хәрәкәтеңне эскалатор хәрәкәтенә яраклаштырып керергә һәм чыгарга әзерләнү); турникетлар аша үткәндә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Метрода, юлларда, шәһәр (авыл) урамнарында үз-үзеңне куркынычсыз тотуның мөһимлеген аңларга ярдәм итү; әхлакый аралашу үрнәкләре («рәхмәт», «рәхмәтлемен сезгә», «гафу итегез», «рәхимле булыгыз», «мөмкин булмасмы» һ. б.) биреп, гади этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.

Җәмәгать урыннарында үз кыланышыңны һәм башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү; балаларның юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләрен үтәмәгән очракта килеп чыккан күңелсез хәлләрне, аларның башка кешеләрнең эмоциональ халәтенә йогынтысын аңлауларына ирешү.

Үзең яшәгән җирлектә транспорт чараларының төрлелегендә ориентлашу күнекмәләрен үстерү: өйдән балалар бакчасына кадәр, үзәк мәйданга һ. б. җирләргә кадәр нинди маршрут автобусы белән барырга мөмкин, әти-әниләр нинди транспорттан файдалана һ. б.

Балаларны машинада утырып йөрү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар урындыгында (креслосында) утыру һәм каеш белән эләктереп кую, машина йөртүченең игътибарын читкә юнәлдермәү, тәрәзәдән башны чыгармау, үзең белән очлы предметлар алмау; үз хәрәкәтләреңне контрольдә тотарга өйрәнү.

Баланы үз фамилиясен, тулы исемен, яшен әйтергә өйрәтү. Тору урынының адресын, телефонын, якындагы тукталыш исемен әйтү һәм полиция хезмәткәренә ярдәм сорап эндәшү күнекмәләрен булдыру.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буйлап, елан- сыман, ике яки өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәнүне дәвам итү; үз хәрәкәтләрең белән идарә итә белергә, велосипедта, 19 йөрү урыннарын билгеләргә өйрәтү.

Балаларның хәрәкәтле уеннар, спорт һәм эстафета уеннары («Каршылыклы юл», «Күңелле ярышлар» һ. б.) оештыру инициативасын хуплау.

Балаларга таныш булган юл билгеләрен, урам чатлары, тукталышлар, ике яклы хәрәкәт, төрле билгеләнештәге транспорт хәрәкәтен файдаланып, җәяүлеләр һәм пассажирлар булып уйнарга мөмкинлекләр бирә торган уен ситуацияләре тудыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү өстендә эшләү.

Танып белү бурычларын үтәгәндә модельләштерү ысулын 19анн19т: күләм һәм киңлек бәйләнешләрен билгеләү («Бүлмә буйлап сәяхәт», «Бала кая киткән?» һ. б.).

Чынбарлыкта булган, вербаль һәм вербаль булмаган уйлап чыгаруларга таянып, эчке программалаштыруның гади операцияләренә өйрәтү: ситуацияләрне уйнап күрсәтү, про- странствода биналарның, транспорт чараларының, җәяүлеләр, юл билгеләренең урнашу макетын һәм моделен ясау күнекмәләре формалаштыру.

Алынган мәгълүматны (су, җир өсте, тимер юл, һава, җигүле транспорт) гомумиләштерергә һәм19аннкыйль эшчәнлектә файдалана белергә өйрәтү («Нәрсә артык?», «Автоюллар лотосы», «Юл доминосы» һ. б.).

Балаларның проблемалы характердагы сораулар бирүләрен хуплау, укыганнары буенча фикер алышуга теләк тудыру («Светофор эшләмәсә, нәрсә булырга мөмкин?», «Әгәр туп транспорт йөри торган юлга тәгәрәп чыкса, нишләргә?» һ. б.). Балаларны проблемалы ситуацияләрне чишәргә генә түгел, ә бәлки үз фикерләрен әйтеп бирергә өйрәтү.

Юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләренең кайберләрен ныгыту максатыннан, уйлап чыгарган әкиятләрдән, тормыш тәҗрибәләреннән алынган хикәяләр, шигырьләрдән, үзләре ясаган рәсемнәрдән (аппликацияләрдән) китап-җыентык төзүләрен хуплау.

Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга мөмкинлек бирү.

Экологик аң алшартларын формалаштыру

Табигатьтә үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыруны дәвам итү. Туган як табигате өчен куркыныч булган кайбер чыганаклар турында сөйләү (агачларны кисү, урман янгыннары, көчле салкыннар, сулыкларны пычрату һ. б.).

Табигать белән кешенең үзара бәйләнеше, әйләнә-тирәнең кешенең сәламәтлегенә йогынтысы турында күзаллаулар булдыру.
Балаларны хуҗасыз хайваннар белән очрашканда мөмкин булган куркыныч хәлләр турында искәртү.

***Комплекслы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар | Интеграция |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Тема: «Җәй безгә сәламәтлек өстәде». | Мөстәкыйльрәвештә үзсәламәтлекләретурында кайгыртырга өйрәтү,җәйге су,һаваның кеше сәламәтлегенә йогынтысы,ничек сәламәт булырга булышулары турында аңлату. | *Танып-белү:* д/у “Нинди агач яфрагы” *Аралашу:*Әңгәмә: “Без җәй көне ничек иттек” |
| | II | Тема: «Велосипедта йөрү кагыйдәләр» | Уң яктан кагыйдәләрне төгәлүтәп велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү,төгәл һәм игътибарлы булырга өйрәтү. | *Аралашу*: Әңгәмә Минем дустым-велосипед” Д/уен”Светофор”, “Хәрәкәт кагыйдәләре” С/р уен. “Транспорт” |
| | III | Тема: «Төркем бүлмәсендә тәртип булырга тиеш» | Балаларны төркем бүлмәсендә чисталык һәм тәртип тотарга өйрәтү, ничек уенчыкларны дөрес итеп урнаштырырга аңлату. | *Аралашу*: Әңгәмә “Ни өчен төркем бүлмәсендә тәртип булырга тиеш” Д/уен”Нәрсә кайда тора” |
| | IV | Тема: «Синең кәрзиндә ниләр бар?» | Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр, җимешләр турындагы күзаллаулар бирү, аларны аерым билгеләре буенча аерырга өйрәтү. | *Иҗади сәнгать*: ябыштыру «Гөмбәләр». “Табышмак әйтәм,тап” Д/уен”Ашарга яраклы, яраксыз гөмбәләр”рәсемнәр карау |
| Октябрь | I | Тема: «Игътибар, грипп» | Үз сәламәтлекләре турында кайгыртырга өйрәтү: авыруның билгеләре, авыруны булдырмау чаралары белән таныштыру, алар турында сөйләргә өйрәтү | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә “Грипп, “Безнең организм ничек эшли” Уен-бирем “Дөрес-дөрес түгел” С/р уен. “Больница” *Иҗади сәнгать*: рәсем “Микроблар” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | Тема: «Җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре» Уен «Без барабыз, барабыз….» | “Куркынычсызлык утравы” билгесе һәм әһәмияте белән таныштыру. Җәмәгать транспортында үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: “Без автобуста барабыз” с/р уен.”Транспорт” *Иҗади сәнгать*: рәсем “Автобус” |
| | III | Тема: «Ут белән сак бул». | Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү, янгын сүндерүче хезмәтенә кызыксыну уяту | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә ”Куркыныч-куркыныч түгел” *Уку*: С. Маршак «Песи өе» Уен-хәл “Синең квартирада янгын, “01” гә шалтырат” |
| | IV | Тема: «Көзге урманда үзеңне тоту кагыйдәләр” | Көзге урманда үзеңне тоту, табигатькә сак карау, “кечкенәтуганнарыбызны” кыерсытмау кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә “ Көзге урманга сәяхәт” Уен-бирем “Гөмбәләрне кәрзингә җый*Иҗади сәнгать*: рәсем «Гөмбәләр». |
| ноябрь | I | Тема: «Кем безнең сәламәтлек турында кайгырта». *Медицина кабинетына экскурсия* | Табиб хезмәте белән танышуны дәвам итү, игътибарлылык, сизгерлек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү. | *Тәҗрибә эшчәнлеге:* Тән температурасын, буйны үлчәү С/р уен. “Тикшерү үзәге” |
| | II | Тема: «Юлда куркынычсызлык». *Дидактик уен* «Юл йөрү кагыйдәләрен бел һәм үтә” | Юлда көтүче куркынычлар турында, юлда йөрү кагыйдәләре турында белемнәрне, светофорның төсләрен, юл билгеләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. | Урамга экскурсия МӘУ.С.Михалков “Скверная история”, Н.Носова “Милиционер” Әңгәмә “Без-җәяүлеләр” |
| | III | Тема: «Өйдә куркыныч әйберләр». | Тормыштагы куркыныч әйберләр,аларны куллану, куллану кагыйдәләрен, турындагы күзаллауларны ныгыту. | Куркыныч әйберләр, шартлар төшерелгән рәсемнәркарау. Әңгәмә:”Тәрәзәдән чыкма” Д/уен “Дөресме бу?” |
| | IV | Тема: «Җылырак киен». | Үз сәламәтлегең турында кайгыртуны дәвам итү, һава торышына карап киенергә, башлык кияргә, шарф бәйләргә күнектерү. | Аралашу: “Ни өчен җылы киенергә кирәк” Уен-бирем “Курчакны |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | тышта йөрергә киендер”<br>Уен-хәл “Незнайка тышта йөрергә чыга” |
| декабрь | I | Тема: «Сәламәтлегеңне үзең кайгырт» | «Вирус, микроб» төшенчәләре кертү. Чирләрдән котылу чаралары белән таныштыру, авырганда терелә чаралары турында сөйләшү. Чыныктыру һәм витаминнарның файдасын аңлату | *Аралашу:*әңгәмә “Ни өчен спорт белән шөгыльләнергә”<br>*Уку:*К. Чуковский «Айболит» (уку һәм өзеген ятлау)<br>Тренинг «Үзеңә массаж»<br>Д/у “Нәрсә-ни өчен”<br>СЯР (ЗОЖ) турында рәсемнәр карау<br>Д/уен«Юыну кирәк-яраклары» |
| | II | Тема: «Игътибар, урам!» | Куркыныч хәлләрдән саклау,саклык, ихтибарлылык сыйфатларын үстерү, таныш түгел кешеләр белән үзеңне тоту кагыйдәләренөйрәнү. | *МӘТ Уку:* “Казлар-аккошлар”<br>Д/уен “Юл билгеләре”<br>с/р уен “Трамвайда сәяхәт”<br>*Иҗади сәнгать: рәсем*“Зебра” |
| | III | Тема: «Чыршы утлары» | Балаларны чыршы уенчыклары белән эш итәргә, зурлар беләнчыршы бизәргә, төгәл, сак булырга, зурлардан башка чыршы утларын кабызмаска өйрәтү | Аралашу: Әңгәмә “чыршыны ничек бизәргә<br>“Гирляндалар матур, ләкин куркыныч”<br>Уен-бирем “Чыршыны бизә”<br>Д/уен “Ватыла-ватылмый”<br>Чыршы уенчыклары ясау |
| | IV | Тема: «Хайваннар белән ничек үзеңне тотарга». | Төрле хайваннар белән очрашканда үзеңне тоту кагыйдәләре турында белемнәр бирү, балаларны хайваннарныңүзләрен тотышын, хәлен аңларга, алар белән аралашырга өйрәтү. Балаларны хуҗасызхайваннар белән очрашкандамөмкин булган куркыныч хәлләр турында искәртү | Аралашу: Әңгәмә<br>“Өйсез песи”<br>МЭТ: Д.Гарифуллин “Песи, песи, пескәем”<br>С.Закир “Песинең зары”<br>“Кыргый хайваннар” рәсемнәр карау.<br>*Иҗади сәнгать: рәсем*“Песи”<br>Уен “Зоопарк” |
| январь | I | Тема”Витаминнар сәламәтлекне ныгыта” | Витаминнар төшенчәсе белән таныштыру, файдалы азыклар, кеше организмы өчен витаминнарның кирәклеге турында белемнәрне ныгыту, балаларда | *Иҗади сәнгать:* рәсем «Витаминнар”<br>Д/ уен “Тәме буенча тап” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ашау культурасы, чама хисе тәрбияләү. | *Тикшерү-тәҗрибә эше*: үз буеңны үлчәү. Яшелчә, җиләк-җимешләр карау. |
| | II | Тема: «01,02,03 һәрвакыт сакта” | Коткару хезмәтләре белән танышу, әхлакъ сыйфатлары тәрбияләү, кешеләргә ярдәм итү теләге уяту. | *Уку:* янгын сүндерүчеләр, полиция хезмәткәрләре, табиблар шигырьләр уку<br>*Социальләштерү:*с/р Уен“Коткару хезмәткәрләре”<br>*Иҗади сәнгать:*рәсем «Янгын сүндерү машинасы”<br>Д\уен “Дөресен тап” |
| | III | Тема: «Хуҗалык җиһазлары- кешенең ярдәмчеләр» | Хуҗалык җиһазларының кулланылышы, аларны куллану турында белемнәрне ныгыту, игътибарлылык, сакчыллык, төгәллек сыйфатлары тәрбияләү. | Рәсемнәр карау<br>*Аралашу*: Әңгәмә “Йорт булышчылары ничек эшли”<br>Д/уен “Электр приборын бел” |
| | IV | Тема: «Сак бул, бозлавык!» | Кышкы юлның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. Бозлы юлда сак йөрүне кисәтү, егылганкешегә беренче ярдәм күрсәтергә тәкъдим итү. | *Аралашу*: Әңгәмә “Сак бул, бозлавык”<br>С/р уен “Травпункт”<br>Уен-бирем “Торырга булыш”<br>Рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* әңгәмә” Кышкы юлда һәм сулыкларда үзеңне тоту кагыйдәләре”, |
| февраль | I | Тема: “ Теш щеткасы белән дуслаш». | Шәхси гигиена кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү,теш щеткасы, теш пастасы, аларның кулланылышы турында күзаллаулар бирү, теш чистарту юллары белән таныштыру. | *Иҗади сәнгать*: рәсем «Теш һәм теш щеткасы».<br>Уку: Г.Юнысова “Тешләр”<br>Д/уен “Тешләр өчен нәрсә файдалы”<br>С/р уен “Теш дәвалау оешмасы” |
| | II | Тема: «Юл билгеләре-ярдәмчеләр»<br>*Сюжетлы-рольле уен* «Шофер» | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен өйрәтүне дәвам итү, тыючы һәм рөхсәт итүче билгеләр белән таныштыру, игътибарлылык тәрбияләү | *Аралашу:*әңгәмә «Куркынычсызлык әлифбасы»<br>Д/уен “Билгене әйт”, “Билгене җый”<br>Уен-бирем “Төгәлләнмәгән рәсем-сызым”<br>Уку: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Т.Александрова «Светофорчик», Ш.Галиев “Светофорның өч сүзе” |
| | III | Тема: «Өйдә берүзем». | Өйдә берүзең калган вакытта үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнү, ишекне ятларга ачмау, электр җиһазларын кушмау, сакчыллык сыйфатлары тәрбияләү. | Аралашу: «Өйдә берүзем.», “Берүзем урамда йөрим”<br>Уен-хәл “Кем ишек кага”.<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Тылсымлы су» | Суга – табигать ресурсына сак караш кирәклеген аңларга өйрәтү, суның үзлекләре белән танышу | Су белән тәҗрибәләр<br>Аралашу: Әңгәмә “Суның үзлекләре”<br>Табигатьтә суның өзлексез әйләнеше<br>Д/уен “Су тегермәне”<br>Уен-бирем “Су тамчысы нәрсәгә охшаган” |
| март | I | Тема: «Гәүдә-матур арка». | Үз сәламәтлегең турында кайгыртырга өйрәнү, физик күнегүләр ясарга теләк уяту, үзенең нәтиҗәсеннән куаныч табу. | Балалар белән гәүдәне ныгыту өчен күнегүләр ясау<br>Скакалка һәм кыршау белән уеннар |
| | II | Тема: «Җәмәгать транспорты тукталышларында тәртип». | Балаларны җәмәгать транспорты тукталышларында үзеңне тоту тәртибенә өйрәтү,игътибарлылык, сакчыллык тәрбияләү | *Аралашу:*әңгәмә «Җәмәгать транспорты тукталышларында үзеңне ничек тотарга»<br>Д/ уен “Юл билгеләре”<br>Уен-хәл”Транспортны ничек урап үтәргә” |
| | III | Тема: “Куркыныч тәкъдим” | Ят кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә, әйләнә-тирәгә игътибарлы булырга өйрәтү, сакчыллык сыйфатлары тәрбияләү. | *Аралашу:*әңгәмә «Ят кешеләр белән аралашу»<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Сак бул, боз китә» | Балаларга боз киткәндә үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлату, елгаларга якын бармаска,куркыныч урыннардан ерак йөрергә, сак булырга өйрәтү. | *Аралашу:*әңгәмә «Сак бул, боз китә»<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга”<br>Рәсемнәр карау |
| апрель | I | Тема: «Спорт –ул сәламәтлек» | Спорт төрләре, Олимпиада турында белемнәрне ныгыту, таныш спорт төрләрен пантомимо белән күрсәтергәөйрәтү, спортка кызыксыну, спорт белән шөгыльләнергә теләк уяту. | Уен-бирем “Тәмамланмаган рәсем-схема”<br>*Аралашу:* әңгәмә «Спорт», “Олимпиада”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | Тема: «Җәяүле культурасы» | Балаларны юлдан чыгу, юлның уң ягыннан йөрү, юлны светофор яшел янганда гына үтәргә кирәк кебек кагыйдәләр белән таныштыруны дәвам итү, игътибарлы һәм сак булырга өйрәтү. | *Иҗади сәнгать:* төзү «Минем урам».<br>*Аралашу:* әңгәмә «Юлны ничек үтәргә”, “уң кул кагыйдәсе”<br>*Уку:* Р.Бәшәр “Кызыл ут”<br>С\Р уен “Җәяүле”<br>Җәяүлеләр өчен юл билгеләрен карау |
| | III | Тема: «Дарулар һәм витаминнар” | Балаларга аптечкадан сораусыз дару һәм витаминнар алырга ярамаганны аңлату, бары нәрсә алырга ярый,нәрсә юкикәнен сорап кына алырга. | *Аралашу:* әңгәмә “Минем аптечка”,<br>Уен-хәл “Нәрсә аптечкада булырга тиеш”<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Яз көне урманда тавышланырга ярамый» | Балаларның урманда үзләрен тыныч тотарга, үзенә, әйләнә- тирәгә игътибарлы булырга, үзебезнең кече туганнарыбызны рәнҗетмәскә өйрәтү. | *Аралашу:* әңгәмә “Урманда үзеңне тоту”<br>Уку: яз көне кошлар турында шигырьләр<br>*Иҗади сәнгать: рәсем* “Яз көне урман”<br>Әвәләү “Кош оясы” |
| май | I | Тема: “Безнең куллар” | Кулларның мөһимлеге, кул беләнбаш миенең бер-берсе белән бәйләнеше, кулны үстергәндәбез телне дә үстерелүе турында төшенчәләр бирү, кул моторикасын үстерүнең кирәклеген төшендерү. | *Физик культура:* х/у “Водяной”<br>Уен-бирем “Шнурны бәйлә”<br>*Аралашу:әңгәмә* “Кеше куллары”<br>Уку: кул турында шигырь.<br>Психогимнастика “Без куллар белән изгелек эшлибез” |
| | II | Тема: «Юлда җәяүле».<br>*Дидактик уен* «Светофорны җый» | Алган белемнәрне кулланып юлдайөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту. | *Физик культура:* хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”, “Чыпчыклар һәм автомобиль”<br>*Аралашу:әңгәмә* “Без урамда уйныйбыз”, “Юл билгеләре”<br>С/р уен. “Автобус”<br>Д/уен “Юл билгеләре” |
| | III | Тема: «Пычрак чебен» | Чебеннәрнең куркынычлыгы турында, шәхси гигиена кагыйдәләрен(ашар алдыннан кулларны юу) үтәргә кирәклеге турында балаларның күзаллауларын ныгыту | Уку: К.Чуковский “Федорино горе”, “Муха-грязнуха” әкияте<br>Уен “Әйе-юк”<br>*Иҗади сәнгать:* |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | *рәсем* “Чебен” |
| | IV | Тема: «Сак бул, яшен». | Балаларны табигатьтә яшен вакытында үз-үзләрен тоту кагыйдәләре (йөгермәскә, агач төбенә качмаска, суга кермәскә, тимергә тотынмаска) белән таныштыру. | Уен: “табышмак әйтәм, тап”<br>Уку: А.Барто “Яшен”, Г.Рәхим “Яшенле яңгыр” |

## 2.3.2. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

### *ЭЛЕМЕНТАР МАТЕМАТИК ТӨШЕНЧӘЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ*

### *Аңлатма язуы*

Балаларның күплек сандагы предметлар турында күзаллаулар үстерү. Билгеләре төрле булган предметлардан төзелгән төркемнең состав өлешләрен күрә белергә өйрәнү.

10 эчендә санау, тәртип буенча санау күнекмәләрен камилләштерү. программа материалын үзләштерү узенчәлекләреннән чыгып, 20 гә кадәр санарга өйрәтү. Икенче дистә саннарының ясалышы белән таныштыру. 0-9 цифрлары белән таныштыру. Натураль саннар арасындагы бәйләнешләрне аңлауларын, саннарның һәрберсен бер берәмлеккә арттыра һәм киметә белүләрен ныгыту. Саннарны уңай һәм кире тәртиптә санау.

5-10 эчендәге саннарның берәмлекләрдән торган составы белән таныштыру. Санны ике кечерәк санга таркату һәм ике кечерәк саннан зуррак саннан зуррак сан төзергә өйрәтү.Балаларны 1,5, 10 тиенлек, 1, 2,5,10 сумлык акчалар белән таныштыру.

Күрсәтмәлелеккә нигезләнеп, кушуга нигезләнгән гади мәсьәләләр төзү һәм чишү.

Предметларны 2-8 тигез кисәккә бүләргә өйрәтү; бөкләү юлы һәм шартлы үлчәү ярдәмендә бүлү. Бөтен белән өлешне чагыштырырга, бөтеннең өлештән зуррак булуын,ә өлешнең бөтеннән кечерәк булуын аңларга өйрәтү.

Башлангыч үлчәү күнекмәләрен бирү. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген, биеклеген үлчәргә һәм чагыштырырга өйрәтү. Шартлы үлчәү ярдәмендә сыеклык һәм чәчелүчән җисемнәрнең күләмен үлчәргә өйрәтү.

Таныш геометрик фигуралар, аларның элементлары һәм кайбер үзенчәлекләре турында күзаллауларын ныгыту. Балаларны чикле территориядә ориентлашырга өйрәтү.

Атна көннәре,ел үйләнәсендәге айларның эзлеклелеге турында күзаллауларын ныгыту. Вакытның кире кайтмавы турында иң гади күзаллау булдыру.Сәгатькә карап, вакытны дөрес әйтә белергә күнектерү.

### *Комплекслы – тематик план*

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | ОББЭ №1 | Билгеләре төрле булган предметлардан төзелгән күплекнең состав өлешләрен бүлү. Сөйләмдә башта, аннары, кадәр, аннан соң, иртәрәк. Соңрак кебек сүз төшенчәләр кулланырга өйрәнү. 10 эчендә санау, тәртип буенча санауны ныгыту. Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. |
| | | ОББЭ №2 | Предметларны төркемли, төркемнән аерым өлешләрен ала белү. 10 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санау. Предметларны 2-4 тигез кисәккә бүләргә өйрәнү. Таныш геометрик фигураларны аерырга, таныш геометрик фигураларны әйтү. |
| | II | ОББЭ №3 | 1.2 саннары белән танышу. 10 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санау.Чикле территориядә ориентлашырга өйрәтү. Өчпочмаклык һәм дөртпочмаклык фигураларын кайбер үзенчәлекләрен ныгыту. |
| | | ОББЭ №4 | 3 саны белән танышу. 10 га кадәрсаннар эчендә башта, аннан соң саннарны әйтә белергә өйрәнү. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген үлчәргә өйрәнү. |
| | III | ОББЭ №5 | 3 саны белән танышу. 10 га кадәрсаннар эчендә башта, аннан соң саннарны әйтә белергә өйрәнү. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген үлчәргә өйрәнү. |
| | | ОББЭ №6 | 4 саны белән танышу. 5 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышу. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген үлчәргә өйрәнү. |
| | IV | ОББЭ №7 | 4 саны белән танышу. 5 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышу. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген үлчәргә өйрәнү. |
| | | ОББЭ №8 | 6 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышу.5 саны белән танышу.Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. Тирә- юньдәге предметларны геометрик фигуралар белән таныштыру. |
| октябрь | I | ОББЭ №9 | 6 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышуны дәвам итү. 6 саны белән танышу. Предметларны 2-8 тигез кисәккә бүләргә өйрәтү. |
| | | ОББЭ №10 | 7 и 8 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышу. 7 саны белән танышу. Бөтенннең аерым өлешләрен дөрес итеп әйтергә күнектерү (икедән бере, дүрттән бере һ.б.).Өчпочмаклык һәм дөртпочмаклык фигураларын кайбер үзенчәлекләрен ныгыту.Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. |
| | II | ОББЭ №11 | 7 и 8 саннарының берәмлекләрдән торган составы белән танышуны дәвам итү. 8 саны белән танышу.Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. Үрнәк буенча тематик композицияне төзи белүне формалаштыру. |
| | | ОББЭ №12 | 9 санының берәмлекләрдән торган составы белән танышу.9 саны белән танышу.Төрле саннан башлап уңай һәм кире тәртиптә санарга өйрәнү. Глазомер төшенчәсен ныгыту. Кагәзҗ битендә ориентлашырга өйрәтү. |
| | III | ОББЭ №13 | 9 санының берәмлекләрдән торган составы белән таныштыруны дәвам итү. 1-9 кадәр саннарны кабатлау. Уч төбенә салып предметларның авырлыгын чагыштыра белү. Геометрик фигураның төсенә һәм формасына карап группалаштыру. |
| | | ОББЭ №14 | 10 саны һәм берәмлекләрдән торган составы белән танышу. 0 саны белән танышу. Бирелгән санга “кадәр”, “аннан соң”саннарны билгеләү. Башлангыч үлчәү күнекмәләре бирү. Сөйләмдә башта, аннары, кадәр, аннан соң, иртәрәк, соңрак кебек сүз- төшенчәләр кулланырга өйрәтү. |
| | IV | ОББЭ №15 | 10 санының берәмлекләрдән торуын таныштыруны дәвам итү. 10 саныбелән таныштыру. 10 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санауны ныгыту.Куппочмаклык турында(өчпочмак, дүртпочмак мисалында) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | таныштыру. |
| | | ОББЭ №16 | 3 саны ике кечерәк санга таркату. 1-9 саннарны таныштыруны ныгыту. Куппочмаклык турында(өчпочмак, дүртпочмак мисалында) таныштыру, аның почмагын, якларын табарга өйрәнү. Ел фасыллары турында ныгыту, көз айлары.бүләргә өйрәтү. |
| ноябрь | I | ОББЭ №17 | 4 санын ике кечерәк санга таркату. 10 эчендә санау, тәртип буенча санау күнекмәләрен ныгыту. Бөтеннең аерым өлешләрен дөрес итеп әйтергә күнектерү . башлангыч үлчәү күнекмәләрен бирү.Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. |
| | | ОББЭ №18 | 5 санын ике кечерәк санга таркату. 15 санына кадәр санның тәртибе белән танышу. Чикле территориядә ориентлашырга өйрәтү ( уң, сул, өскә, аска). |
| | II | ОББЭ №19 | 6 санын ике кечерәк санга таркату. 15 санына кадәр санның тәртибе белән танышуны дәвам итү. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметның күләмен үлчәү. Бирелгән шарт буенча ориентлашырга өйрәнү. |
| | | ОББЭ №20 | 7 санын ике кечерәк санга таркату. 20 санына кадәр санның тәртибе белән танышу. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметның озынлыгын үлчәү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү. |
| | III | ОББЭ №21 | 8 санын ике кечерәк санга таркату. 15 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санау.Шартлы үлчәү ярдәмендә предметның озынлыгын үлчәү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү. |
| | | ОББЭ №22 | 9 санын ике кечерәк санга таркату.20 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санау.Шартлы үлчәү ярдәмендә предметның биеклеген үлчәү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү. |
| | IV | ОББЭ №23 | 10 санын ике кечерәк санга таркату. Бирелгән санга башта , аннары, төшеп калган саннарны табу. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларны үлчәргә өйрәнү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү. |
| | | ОББЭ №24 | 4 санын ике кечерәк санга таркату. 10 эчендә санау, тәртип буенча санау күнекмәләрен ныгыту. Бөтеннең аерым өлешләрен дөрес итеп әйтергә күнектерү . башлангыч үлчәү күнекмәләрен бирү.Атна көннәрен билгеләү һәм ныгыту. |
| декабрь | I | ОББЭ №25 | 1, 5, 10 тиенлек һәм 1, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыру. Балаларны чикле территориядә ориентлашырга өйрәтү.Күппочмаклык турында күзаллауларын ныгыту, аларның зурлыгына һәм формасына карап классификацияләү. |
| | | ОББЭ №26 | 1, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыруны дәвам итү.Вакыт төшенчәсе, ком сәгате белән таныштыру. |
| | II | ОББЭ №27 | 1, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыру,санау һәм алыштыру юлларын карау. 20 гә кадәр саннар белән танышу. Вакыт төшенчәсе, ком сәгате белән таныштыру. |
| | | ОББЭ №28 | 1, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыруны дәвам итү. Вакытны сиземли белергә өйрәтү. Вакытка карата үз эш гамәлләреңне көйли елергә күнектерү. Бирелгән вакыт эчендә 20 кадәр санау. |
| | III | ОББЭ №29 | 1, 5, 10 сумлык һәм 1, 5, тиенлек акалар белән таныштыруны таныштыруны дәвам итү.Чәчелмә материаллар белән үлчәү алымнарын өйрәтү. Предметның өлешләрен билгеләүне ныгыту. |
| | | ОББЭ №30 | Шартлы билгеләр ярдәмендә чәчелмә материалларны үлчәргә дәвам итү. Сәгать берәмлекләре белән таныштыру. Сәгать макетында вакытны билгеләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | ОББЭ №31 | Шартлы билгеләр ярдәмендә сыеклыкны үлчәргә өйрәтү. 10 саны 1 санга арттыру, кимү тәртибен ныгыту. 5 минут эчендә вакыт сиземләвен камилләтерү. |
| | | ОББЭ №32 | 10 санын 2 кечкенә санга таркату һәм ике кечкенә саннан 10 санын барлыкка китерү. Ел фасылларының ай исемнәре эзлеклелеген ныгыту. |
| гыйнвар | II | ОББЭ №33 | Кушуга бер гамәлле мәсьәләләр чишү. Тирә-яктагы предметларда геометрик фигураларны күрә белү. Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №34 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | III | ОББЭ №35 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү. Шартлы үлчәү ярдәмендә сыеклык күләмен үлчәргә өйрәнү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №36 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү.1, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыру һәм җыю, выклау.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | IV | ОББЭ №37 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү. Вакыт белән таныштыруны дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | | ОББЭ №38 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишүне дәвам итү. 20 гә кадәр саннарның эзлеклелеген камилләштерү. Бербөтенне 8 тигез өлешкә бүләргә өйрәтү һәм чагыштыру. |
| февраль | I | ОББЭ №39 | Кушуга бер гамәлле мәсьәләләр чишүне дәвам итү.Үрнәк буенча санау күнекмәләрен камилләштерү. Шакмак буенча туры кисемтәнең озынлыгын үлчәргә өйрәнү. Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №40 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү. Кышкы айларны өйрәнү. Берәмлекләрдән ссанны тәзәргә өйрәнү. |
| | II | ОББЭ №41 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү. Сөйләмдә башта, аннары, кадәр, аннан соң, сүз-төшенчәләрен кулланырга өйрәтү.Шакмак буенча туры кисемтәнең озынлыгын үлчәргә өйрәнү. Предметның зурлыгын күзаллауны үстерү. |
| | | ОББЭ №42 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишү. Предметның авырлыгын күзаллауны үстерү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү,телдән әйтеп. |
| | III | ОББЭ №43 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишүне дәвам итү. Шартлы үлчәү ярдәмендә предметларның биеклеген үлчәргә өйрәнү. Сәгатькә карап вакытны билгеләү (1 сәгатҗкә якын төгәллек белән). Логик фикерләүне үстерү. |
| | | ОББЭ №44 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү һәм чишүне дәвам итү. Геометрик фигураларны күзаллауны ныгыту, кагәзь битендә ясау.Логик фикерләүне үстерү. |
| | IV | ОББЭ №45 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү. Шартлы билгеләнгән пространствода ориентлашырга өйрәнү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ОББЭ №46 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзү. Геометрик фигураларны модельләштерергә өйрәтү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| март | I | ОББЭ №47 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне 10 га кадәр дәвам итү.Бербөтенне 8 тигез өлешкә бүләргә өйрәтү һәм чагыштыру.Сәгатькә карап вакытны билгеләү (1 сәгатькә якын төгәллек белән). Логик фикерләүне үстерү. Хәтерне үстерү. |
| | | ОББЭ №48 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Хәтерне үстерү. |
| | II | ОББЭ №49 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне 10 га кадәр дәвам итү. Шартлы үлчәм ярдәмендә предметларның озынлыгын үлчәргә өйрәтү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Атна көннәре, ел әйләнәсендәге айларны күзаллауны ныгыту. |
| | | ОББЭ №50 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Санны ике кечерәк санга таркату һәм ике кечерәк саннан зуррак саннан зуррак сан төзергә өйрәнү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | ОББЭ №51 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Бөтен һәм өлешне чагыштырыргаөйрәнү.Таныш фигураларны чынбарлыктагы предметларда күрә белү. |
| | | ОББЭ №52 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Атна көннәре эзлеклелеген ныгыту. Геометрик фигураларны моделәштерергә өйрәтү. Форманың пространстволы үзләштерүне үстерү. |
| | IV | ОББЭ №53 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Күләмле геометрик фигураларны төзүне ныгыту.20 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санауны ныгыту. |
| | | ОББЭ №54 | Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне 10 га кадәр дәвам итү.Бербөтенне 8 тигез өлешкә бүләргә өйрәтү һәм чагыштыру.Сәгатькә карап вакытны билгеләү (1 сәгатькә якын төгәллек белән). Логик фикерләүне үстерү. Хәтерне үстерү. |
| апрель | I | ОББЭ №55 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Предметның озынлыгын күзаллауны үстерү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №56 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Атна көннәре, ел әйләнәсендәге айларны күзаллауны ныгыту.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | II | ОББЭ №57 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү.Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Пространствода иң гади график мәгълүматларны укырга өйрәтү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №58 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | ОББЭ №59 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү..Санны ике кечерәк санга таркату һәм ике кечерәк саннан зуррак саннан зуррак сан төзергә өйрәнү. Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №60 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Геометрик фигураларны ң кайбер үзенчәлекләрен ныгыту. Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | IV | ОББЭ №61 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. 20 га кадәр уңай һәм кире тәртиптә санауны ныгыту.Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| | | ОББЭ №62 | 10 га кадәр алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзүне дәвам итү. Шакмаклы кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү.  Мөстәкыйль рәвештә пространствода хәрәкәт итү. Логик фикерләү, хәтер, игътибарлылыкны үстерү. |
| май | I | Үткән материалларны кабатлау өстендә эш. | |
| | II | | |
| | III | | |
| | IV | | |

## *ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК, СОЦИАЛЬ ДӨНЬЯ, ТАБИГАТЬ ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ*

### *Аңлатма язуы*

*«Танып белү үсеше»  белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Балалар бакчасында балаларның (кечкенәләр, үзеннән зурраклар, яшьтәшләре, малайлар-кызлар, төркемгә килгән «яңа» балалар белән) туган телдә аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

Төрле эшчәнлек төрләрендә балаларга туган телдә үзара һәм өлкәннәр белән бай, эчтәлекле аралашу өчен шартлар тудыру.

Элементар әхлак кагыйдәләренә өйрәтү, әхлак буенча аралашу үрнәкләре бирү, сөйләмдә татар халык фольклорын (мәкальләр, әйтемнәр, юаткычлар һ. б.) куллануга теләк уяту.

Бөтен кешелек өчен уртак байлык булган патриотизм хисләренең әхлакый нигезен булдыру өчен шартлар тудыру (гаиләсенә, балалар бакчасына, туган ягына, иленә, әйләнә- тирә дөгел әргә мәхәббәт).

Гаиләң һәм аның тарихы турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай, абый-эне, апа-сеңел, туганнан туган абый-апалар), гаиләдәге урыны, туганлык җепләре һәм гаилә эчендә бәйләнешләр («Мин әтигә – ул, ә әбигә – онык», «Газизә апа – минем Фатыйма әбиемнең кызы»), әти-өниләрнең һәм туганнарның һөнәр һәм шөгыльләре турында күзаллаулар булдыру; туганнарның фотографияләрен карап, баланың әти-әниләре һәм башка туганнары белән тышкы охшашлыгына басым ясау.

Үзенең уңыш һәм казанышларына, әти-әниләренең, якын кешеләренең, дусларының, Олимпия уеннары спортчыларының, артистларның халыкара конкурсларда яулаган уңыш һәм казанышларына шатлык, горурлык хисләре тәрбияләү.

Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелеген хуплау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган белемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.

Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кулдан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта булган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын, мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк режиссерлык уеннарына булышлык күрсәтү.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау, Идел буе, халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, әти-әниләр һәм кунаклар алдында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.

Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәүне, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.

Белем өлкәсе “Социаль- шәхси үсеш” җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.

Планлаштыруинтеграция принциплары, төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Минем туган җирем | 1. Туган шәһәребезгә (авылыбызга) карата горурлык хисе тәрбияләү.<br>2. Үстерелешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.<br>3. Балаларның Ватаныбыз, республикабыз (шәһәр һәм авыл) һәм аның символикасы турындагы мәгълүматларын арттыру. |
| | II | Әңгәмә «Минем гүзәл халкым» | 1. Туган җирең, халкың, телең белән горурлану хисе тәрбияләү, Татарстанда яшәгән башка халыкларның мәдәниятен хөрмәтлә<br>2. Балаларда халкыбызның туган җиренә, теленә, үткәненә, тарихына, мәдәниятына кызыксыну үстерү.<br>3. Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл кулланырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | Туган ягым язучылары | 1. Балаларда язучыларыбыз иҗатына карата кызыксыну уяту, аларга карата ихтирам тәрбияләү.<br>2. Табышмак, мәкальләр ярдәмендә логик фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Сорау – җавап тибында аралашу вакытында баланы булган белемнәренә таянып фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерым карарга килергә һәм берләштерергә өйрәтү. |
| | IV | Тирә-якны күзәт. | 1.Рус һәм татар халык культурасы белән танышу.<br>2.Көзгә кагылышлы сузләрне актив сөйләмгә кертү.<br>3.Көзге айларның элекеге атамалары ярдәмендә сүзлекне баету. |
| октябр | I | Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә | 1.Балаларга көзге байлыкның халыкка шатлык, куаныч китерүен төшендерү, бу байлыкларны тудыручы игенчеләр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү/<br>2. Балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3. Игенченең мактаулы һәм авыр хезмәте, икмнең нинди юллар аша табынга килүе турында тасвирлап |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сөйләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | Кем безгә икмәк үстерә | 1.Профессияләр турында күзаллауны киңәйтү.<br>2.Җирдә эшләүчеләр һәм аларның профессияләре белән таныштыру.<br>3.Зурлар хезмәтенә хөрмәт, икмәккә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | Ашханәгә экскурсия | 1. Балаларда өлкәннәр хезмәтенә ихтирам тәрбияләү.<br>2. Көндәлек туклану режимы турында төшенчә бирү, һәр төр ашка туры килүчеризыклар, аларның сәламәтлеккә тәэсирен ачыклау, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Өйрәнелгән сүзләрнең сөйләмдә кулланылышын активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрнең мәгънәсен аңларга өйрәтү. |
| | IV | Ипине ничек үстерәләр? | 1.Җир йөзендәге иң зур байлыкларның берсе булган икмәк турындагы белемнәрне, икмәк үстерүче хезмәт кешеләренең атамаларын ныгыту.<br>2.Безнең өстәлләргә икмәк ничек килә, без ашаганчы нинди юллар үтүен сөйләү.<br>3.Икмәккә сакчыл караш, аны үстерүче кеше хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү |
| | V | Танышу уены: «Әбиемнең серле сандыгы» | 1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмдә парлы, кушма, ясалма сүзләр куллану күнекмәләре бирү.<br>3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру. |
| ноябрь | I | Федора әбидә кунакта | 1.Йорт җиһазлары һәм табак-савыттөшенчәләре турындагыбелемнәрне ныгыту.<br>2.Табак-савытларны (чәй, аш,кухня), йорт җиһазларын (йокы,кунак, аш бүлмәләре) төркемнәргәбүлү.<br>3.Предметларны теге яки бубилгеләре, кулланылышлары буенча төркемнәргә бүләргә өйрәтү. |
| | II | Ферма | 1.Авыл хуҗалыгына карата кызыксыну уяту.<br>2.Фермер хөнәрчелегенә хөрмәт тәрбияләү.<br>3.Бу хезмәтнең авыр һәм бик мөһим булуын аңлату. |
| | III | Библиотекага экскурсия<br>«Бар хезмәт тә яхшы» | 1.Профессияләр турындагыкүзаллауларны киңәйтү.<br>2.Библиотекарь хезмәте белән таныштыру.<br>3.Зурлар хезмәтенә хөрмәттәрбияләү. |
| | IV | Боз һәм бозлыклар | 1. Балаларда табигать күренешләрен белергә омтылыш, үз фикерен әйтә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Балаларның табигать объектлары белән кызыксынучанлыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен, сүз байлыкларын үстерү.<br>3. Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү,әйләнә-тирә чынбарлыкка нәфасәти мөнәсәбәт формалаштыруны дәвам итү. |
| декабрь | I | Паркка экскурсия. «Килеп җитте матур кыш» | 1. Балаларда кызыксыну уяту, табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Чагыштырып тасвирлый белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның кыш, кар үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. |
| | II | Әңгәмә. «Паркта минем | 1. Балаларда үсемлекләргә, кошларга, хайваннарга карата сак караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күргәннәрем» | 2. Экологик фикер йөртү, иҗади хыял сәләтләрен үстерү.<br>3. Табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр ту-рындагы белемнәрен системалаштыру һәм тирәнәйтү. |
| | III | Бизәлгән мәйданчыклар буенча сәяхәт. | 1. Балаларда табигатькә сак караш, бизәлгән мәйданчыкларга соклану, бәйрәм хисләре уяту..<br>2. Чагыштырып тасвирлый белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның кыш, кар үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. |
| | IV | Паркка экскурсия . | 1.Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтергә теләк уяту. Ботакларының урнашуы, агачта калган орлыклары буенча агачларны аерырга өйрәтү. Кышкы пейзажның матурлыгын күрергә өйрәтүне дәвам итү.<br>2.Январь ае турында әйтемнәр, мәкальләр, бу айдагы бәйрәмнәр турындагы белемнәрне ныгыту.<br>3.Табигатьтә үз-үзеңне тоту, үз сәламәтлегең, әйләнә- тирәдәгеләрнең сәламәтлеге турында кайгырту турындагы белемнәрне формалаштыру. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |
| январь | | | |
| | III | Танышу уены: «Әбиемнең серле сандыгы» | 1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренәкызыксыну тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмдә парлы,кушма, ясалма сүзләр куллану күнекмәләре бирү.<br>3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдәкуллануны системалаштыру. |
| | IV | Январь һәм февраль айларының үзләренә хас үзенчәлекләре | 1.Халык әйтемнәре буенча табигатьне күзәтергә өйрәнү.<br>2.Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы өчен бик үк яхшы булмаган февраль ае, гомумән кыш турындагы белемнәрне ныгыту.<br>3.һава торышын күзәтергә, күзәтүләрне шәхси тәҗрибә белән бәйләргә, күзәтү көндәлеген алып барырга өйрәтү. |
| февраль | I | Безнең тирә-юньдәге куркынычлар | 1.Өйдә һәм урамдагы куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү.<br>2.“Ашыгыч ярдәм”, янгын хезмәте, полицияләрнең телефон номерлары белән таныштыру, мөстәкыйль рәвештә номерны җыярга өйрәтү.<br>3.Ярдәм турында башлангыч төшенчә бирү. |
| | II | Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) | 1. Хезмәт кешесенә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Сөйләмдә ясалма сүзләр, грамматик формалар куллану күнекмәләре бирү, баланың истә калдыру сәләтен, хәтерен үстерү.<br>3. Яңа сүзләрне бәйләнешле сөйләмдә кулланырга өйрәтү. |
| | III | Кемнәр алар ил сакчылары? | 1. Ватанны саклау теләге, әтиләре белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның уй-фикерләү сәләтен камилләштерү.<br>3. Балаларга Ватанны саклаучылар турында башлангыч төшенчә бирү. |
| | IV | Фикер алышу: «Дуслык – бөек көч» | 1. Төрле милләт халыкларына хөрмәт, дуслык хисләретәрбияләү.<br>2. Балаларның акыл, хәтер, логик фикер йөртү сәләтен үстерү.<br>3. Идел буе халыклары турында балаларның белемнәрен баету. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| март | I | Иң якын һәм кирәкле әниләр турында | 1.Әниләрнең өйдә һәм эштәге хезмәте турындагы белемнәрне ныгыту.<br>2.Хатын-кызларга мәхәббәт, хөрмәт, һәм кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.<br>3.Профессияләр турында белемнәрне тирәнәйтү. Ата-аналарның эш урынын әйтә өйрәтү. |
| | II | Кошларны күзәтү. «Безнең канатлы дусларыбыз» | 1. Балаларда кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыр-тучанлык хисе тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклегентөшендерү.<br>2. Тышкы билгеләренә (төсе, зурлыгы), үз-үзләрентотышларына, тавышларына карап, кышлаучы һәм күчмәкошларны аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның кышлаучы кошлар турындагы белемнәренныгыту. |
| | III | Нәрсә ул Кызыл китап? | 1. Балаларда күмәк сөйләшүдә катнашу, бер-береңне тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру.<br>2. Балаларның сорауларга ашыкмыйча, эзлекле итеп җавап бирү сыйфатын, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларның табигатьне саклау турындагы күзаллауларын киңәйтү, «Кызыл китап» турындагы белемнәрен тирәнәйтү, |
| | IV | Нәрсә ул Кояш системасы? | 1.Тирә-юньне,табигатьне аңларга һәм сакларга сәләтле со-циаль актив, иҗади шәхес тәрбияләү.<br>2.Балаларның аралашу осталыкларын,вакыйгаларның яңа эзлеклелеген төзи белү күнекмәләрен үстерү.<br>3.Балаларның Кояш системасытурындагы белемнәрен камилләштерү |
| апрель | I | Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт» | 1.Балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен гомумиләштерү һәм балаларда шигърият белән кызыксыну тәрбияләү.<br>2.Телнең сәнгатьлелеген камилләштерү, хәтер сәләтенүстерү.<br>3.Шигырьдәге төп фикерне аңларга, әсәрне сәхнәләштерергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | Әдәби викторина. «Мультфильмда кунакта» | 1.Г.Тукай әкиятләре, шигырьләре аша балаларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү.<br>2.Балаларның игътибарлылыкларын, хәтерләрен, фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Таныш әдәби сюжетлар буенча балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү. |
| | III | Паркка экскурсия. «Туган якка яз килде» | 1.Табигатькә карата сак караш тәрбияләү.<br>2.Ситуативсораулар ярдәмендә балаларның логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәләрен камилләштерү |
| | IV | Ветераннар белән очрашу.<br>«Алар безгә Җиңү бүләк итте» | 1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү.<br>3. Ветераннарыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында белемнәрен киңәйтү. |
| май | I | Спортчылар белән танышу. | 1. Спорт мәктәбе турындагы белемнәрне ныгыту, киңәйтү<br>2. Сөйләмдә ясалма сүзләрне куллану күнекмәләрен бирү<br>3. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | Китапханәгә экскурсия | 1. Балаларда китапханәче хезмәтенә карата ихтирам,китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларга китапханәче һөнәренең мөһимлеген аңлату. |
| | III | Без барабыз мәктәпкә | 1. Балаларда белем алуга омтылыш уяту.<br>2. Сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгынүстерү.<br>3. Балаларның мәктәп турында күзаллауларын киңәйтү. |
| | IV | Минем туган җирем | 1. Туган шәһәребезгә (авылыбызга) карата горурлык хисе тәрбияләү.<br>2. Үстерелешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.<br>3. Балаларның Ватаныбыз, республикабыз (шәһәр һәм авыл) һәм аның символикасы турындагы мәгълүматларын арттыру. |

### 2.3.3. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ»белем бирү өлкәсе

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

**МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШУ**

«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балада китап укуга кызыксыну **һәм**ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә **һәм*белем бирү бурычларын*** билгели.

Балаларны танып белү әдәбиятына һәм матур әдәбиятка, халык авыз иҗатына тарту, әдәби кичерешләр байлыгын формалаштыру.

Китапның белем чыганагы икәнлегенә төшендерү. Китапка сакчыл караш тәрбияләү, мөстәкыйль рәвештә китапның рәсемнәрен карарга, эчтәлеген яңадан тыңларга теләк уяту.

Зур булмаган проза текстларының эчтәлеген ачып бирә белергә һәм кечкенәрәк шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләргә, текстларны рольләргә бүлеп укуда, әсәрләрне сәхнәләштерүдә катнашырга өйрәтү.

Татар халык мәкаль-әйтемнәре белән таныштыру, ал арның мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Балаларның иҗат чагылышлары, иҗат итү башлангычлары өчен (күрсәтмә материалга нигезләнелгән такмазалар, юаткычлар, хикәяләр) шартлар тудыру.

Балаларга әкиятләрнең (шулай ук татар халык әкиятләренең) жанр үзенчәлекләрен аңлатуны дәвам итү. Әкият геройларының эш-гамәлләренә бәя бирергә теләк уяту, алар- ның үз-үзен тотышларындагы яшерен мотивларны аңларга булышу

***Тәкъдим ителә торган әсәрләр***

***Балаларга уку өчен***

*Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләр, әйтешләр, бармак уеннары:* «Җепсез орчык..»;

«Ваттым мичкә,яктым мичкә..»; «Бака, бака, бакырган...»; «Мич башында биш мәче...»; «Без уйныйбыз, уйныйбыз...»; «Ямьле бәйрәм көн иде...»; «Тилгән,тилгән...»; «Карга килде - казан асты...»; «Саескан сары май китерә...»; «Күпер башында..»; «Миңлебай»; «Абагага бага-бага...»; «Әйт әле, чикерткә...»; «Тор-тор, торналар...»; «Карга әйтә...»; «Торыгыз, тор, хуҗалар...»; «Яңгыр ява, томан төшә...».

*Әкиятләр нәм легендалар:* Татар халык әкиятләре: «Ай белән Кояш»; «Ялкау малай»; «Кәкре каенга терәткән?»; «Алтын бөртекләр»; «Бүләк кемгә?»; «Кола ат»;Легендалар: «Зөһрә кыз»; «Ни өчен бакалар бакылдык булып калганнар»; «Ни өчен,Чәберчек килмичә,боз китми икән?»; украин халык әкияте «Сандугач»; Рус халык әкияте «Казлар-аккошлар»; эстон халык әкияте «Куянның ирене нигә ярык?»; корея халык әкияте «Тату туганнар"Төрекмән халык әкияте"Икмәк",калмык халык әкияте"Күңелле чыпчык белән күңелсез карга",удмурт халык әкияте"Тычкан белән Чыпчык".

*Әдәби әкиятләр:* Г. Тукай. «Шүрәле» (өзек); А,Алиш«Сертотмас үрдәк», ; С,Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле»; И. Дәүләтша. «Үрдәк беренчелекне алган»; Ә. Гаффар. «Суалчан кунакка бара»; А. Алиш. «Каз белән Аккош»; Р. Вәлиева. «Ялкау Карга баласы».

*Шигърият:*Ә. Синегулов. «Татарстан җирләре»; М. Җәлил «Көз җитте»; Х Халиков. «Дәү әнием-бакчачы»; Н.Мадьяров. «Балан»; Р,Вәлиева. «Ашлар солтаны»; З.Туфайлова «Минем гаиләм»; ГЛатыйп. «Кыш килде»; Р.Вәлиева. «Кәләпүшем,кәләпүшем»; ГЮнысова. «Светофор»; Э. Мөәминова. «Фокусчы»; РКорбан. «Җәлил турында җыр»; Х Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә.»; Ә Габиди. «Минем гөлләрем»; Н,Мадьяров. «Көләч яз»; Г Юнысова. «Кара»; Х.Халиков. «Китап докторы»; Йолдыз. «Сәлам ,галәм».Г.Юнысова"Зарядкага бас"Г.Тукай"Эш беткәч уйнарга ярый".Б.Рәхмәт"Мәктәпкә".

*Төрле ил язучылары* ***һәм****шагыйрьләре әсәрләре:* А. Бар- то. «Берүзем», Р. Вәлиева тәрҗемәсе; Н. Думбадзе. «Энә», Р. Миңнуллин тәрҗемәсе; А. Барто. «Елга», 3. Мансур тәрҗемәсе; А. Тимиркаев. «Якшәмбе көн балыкта», Р. Миңнуллин тәрҗемәсе.

*Чәчмә әсәрләр:* А. Алиш. «Әбиләрдә кунакта»; Н. Фәттах. «Ирек, Алмас һәм Җәлил»; Г. Мөхәммәтшин. «Ак песи», «Велосипедлы Мөнир»; К. Ушинский. «Иртәнге нурлар», Ф. Басыйров тәрҗемәсе; К. Ушинский. «Сыер», А. Әхмәт тәрҗемәсе; Я. Тайц. «Сөт елгасы», К. Котдусова тәрҗемәсе; Р. Фәхреддин. «Ашау әдәпләре»; Г. Бакир. «Йорт салалар»; Җ. Дәрзаман. «Актырнак белән Назбикә»; М. Хәсәнов. «Көн җылынды»; Р. Мингалим. «Канатларың булса...»; 3. Әхмәров. «Агачлар да авырый»; Ф. Сафин. «Кызык итте...»; Ф. Зариф. «Татлы җәй»; Ә. Хәсәнов. «Бал дәвалый».

*Рольләргә бүлеп сөйләү өчен:* Р. Вәлиева. «Керпе белән бала»; Х. Халиков. «Оныткан»; Р. Миңнуллин. «Авыл малае белән шәһәр малае...»; М. Хөсәен. «Безнең дусларыбыз».

***Яттан өйрәнү өчен***

М.Җәлил. «Көз җитте»;ГЛатыйп. «Кыш килде»; Г.Юнысова. «Светофор»; Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә»; Г.Юнысова. «Кара»; . «Зарядкага бас»; Б.Рәхмәт«Мәктәпкә»;

**Өстәмә әдәбият**

*Шигърият:* Г. Гыйльманов. «Чишмәгә бардык»; Ә. Ерикәй. «Чисталык сөябез»; В. Хәйруллина. «Шифа чәе»; Д. Гарифуллин. «Үстем»; И. Иксанова. «Иртә»; Н. Мадьяров. «Әниемә булышам»; Р. Фәйзуллин. «Миләш»; Л. Шәех. «Безнең ишегалдында»; Р. Корбан. «Ныграк авыртыр иде»; Ф. Зыятдинова. «Татарча белмәүче кәҗәләр»; Ш. Җиһангирова. «Кем хаклы?»; М. Ногман. «Кыш килде»; Р. Миңнуллин. «Почмакта торам»; Г. Зәйнашева. «Әбиемне яратам», «Сабан туе»; Г. Морат. «Туган тел»; М. Фәйзуллина. «Бал корты».

*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр:* Ә. Бикчәнтәева. «Өстәл янында»; Н. Кәримова. «Кое чыпчыгы»; Р. Мингалим. «Дөресе аның шулай...»; В. Монасыйпов. «Шифалы табиблар»; Г. Таһирова. «Кечкенә миләш»; Г. Мөхәммәтшин. «Гап-гади Инсаф»; Т. Әйди. «Дачада».

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара» | 1. Халык авыз иҗаты аша балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.<br>2. Балаларда әдәби әсәрләрне тыңлый белү сәләтен үстерү.<br>3. Хикәя эчтәлеге буенча сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү. |
| | II | В.Осеева “Тылсымлы сүз”Хикәянең эчтәлеген сөйләү. | Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген дөрес интонация белән сөйләү күнекмәсе тәрбияләү.<br>Хәтер сәләтен үстерү.<br>Матур әдәбият аша балаларның сөйләмендә ягымлы сүзләр кулլануларына ирешү. |
| | III | Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре» | 1. Туган ил, туган йортны ярату, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның фикерләү сәләтен, диалогик сөйләм телен үстерү.<br>3. Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирә белергә өйрәтү |
| | IV | А.Алиш иҗаты белән танышу | 1. А.Алиш әсәрләре буенча балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.<br>2. Әкиятләр, хикәяләр ярдәмендә балаларның сөйләм телен үстерү.<br>3. А.Алиш китаплары һәм иллюстрацияләр аша әсәрләрен искә төшерүсорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү |
| октябрь | I | Шигырь ятлау: М.Җәлил. «Көз җитте» | 1. Көз фасылының үзенә генә хас булган матурлыгын һәм гүзәллеген күрә белү, соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыгын арттыру, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Шигырьнең эчтәлеген, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен аңлату, шигырьне яттан, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү |
| | II | Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны» | 1. Балаларда эстетик тойгылар, икмәккә һәм башка ризыкларга сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның әдәби әсәрне тыңлый, сәнгатьле сурәтләү чараларын күрә белү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларның әдәби багажын шигырьләр, табышмаклар, тизәйткечләр белән тулыландыру |
| | III | Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм» | 1. Балаларда гаилә әгъзаларына ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>2. Балаларда матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән тыңлый белү, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. «Тату гаилә» дигән төшенчәнең асылын бирү |
| | IV | Хикәянең эчтәлеген сөйләү:С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?» | 1. Балаларда сөйләм әдәбе, бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Күрсәтмә образлы фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга һәм хәтердә калдырырга ярдәм итү, текстның эчтәлеген тулы итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| ноябрь | I | | |
| | II | Шигырь уку: Р.Вәлиева. | 1. Балаларда матур әдәбият аша милли киемнәргә карата кызыксыну уяту, аларның |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Кәләпүшем, кәләпүш» | үзләренә генә хас булган нәфис бизәлешенә, уңайлылыгына соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру; сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.<br>3. Милли киемнәрне аера һәм аларның исемнәрен, үзенчәлекләрен әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | «Зөһрә йолдыз" Легенда уку. | 1. Матур әдәбият әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен , сәнгатьле сөйләмен үстерү.<br>3. Легенданың эчтәлеге буенча куелган сорауларга җавап алуга ирешү. |
| | IV | Шигырь ятлауГ.Юнысов "Светофор". | 1. Балаларда матур әдәбият әсәрләренә мәхәббәт тәр -бияләүне дәвам итү.<br>2. Шигырь аша светфор турындагы белемнәрен ныгыту.<br>3. Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. |
| декабрь | I | Шигырь ятлау: Г.Латыйп. «Кыш килде» | 1. Балаларда шигырь юллары аша кышкы табигатькә соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү.<br>3. Шигырьнең эчтәлеге буенча куелган сорауларга дөрес җавап алуга ирешү; халык сынамышларына кызыксыну уяту. |
| | II | Иң бәхетле көн"<br>Ф.Яруллин | 1. Балаларда матур әдәбият әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү.<br>2. Эчтәлеген аңлап сөйли белүне ныгыту.<br>3. Үзара дустанә мөнәсәбәт булдыру. |
| | III | "Хуш киләсез, кунаклар" хикәя уку. | 1. Балаларда кунакчыллык, кунакларга карата хөрмәт сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.<br>3. Сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү, кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, өстәл әзерләү күнекмәләре булдыру |
| | IV | "Кыш бабай бүләк өләшә"<br>Яңа ел шигырьләре калейдоскобы. | Яңа елга багышланган шигырьләрне искә төшерү, аларны сәнгатьле итеп сөйләү. |
| гыйнвар | I | | |
| | II | Шигырь уку. Э. Мөэминова "Фокусчы" | 1. Балада һөнәр осталарының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү<br>2. Яңа сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, диалогик сөйләм үстерү. 3. Бирелгән шигырь аша фокусчының хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү. |
| | III | Шигырь уку. Ә. Ерикәй. "Безгә тынычлык кирәк" | 1. Балага дус булыргакирәклеген төшендерү, аларда дуслык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү.<br>2. Фикерләү, игътибарлылык сәләтен, сөйләм телен үстерү.<br>3. Шигырьдәге төп фикерне аңлау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш» | 1. Балаларда матур әдәбият аша милли киемнәргә карата кызыксыну уяту, аларның үзләренә генә хас булган нәфис бизәлешенә, уңайлылыгына соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру; сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.<br>3. Милли киемнәрне аера һәм аларның исемнәрен, үзенчәлекләрен әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. |
| февраль | I | Әкиятне дәвам итеп сөйләү. «Кучтәнәч»тә кунакта» | 1. Балаларда матур әдәбият белән кызыксыну һәм аны ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Үз фикерен ана телендә эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп әйтеп бирә белү, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Сорауларга тулы, төгәл җавап бирергә, геройларның кылган эшләренә, әхлакый сыйфатларына бәя бирә белергә, әкиятләрне һәм мәзәкләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.Сүзлек:рәссам, тылсым, сихер, үтенеч, кучтәнәч. |
| | II | «Тигез хокук белән яшик бу җирдә!» | 1. Балаларга дус булырга кирәклеген төшендерү, аларда дус-лык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү.<br>2. Фикерләү, игътибарлылык сәләтен, сөйләм телен үстерү.<br>3. Кеше бер-берсе белән, нинди милләттән булуына карамастан, туганнарча аралашып яшәүгә хокуклы булу төшенчәсен бирү.<br>Сүзлек: хокук, җир шары, дөнья картасы, дуслык, тынычлык. |
| | III | Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар» | 1. Табигатькә, урманда үсүче үсемлекләргә сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле, эзлекле итеп әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Туган ягыбызда үсүче дару үләннәренең файдалы үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирүне дәвам итү. Сүзлек: мәтрүшкә, бака яфрагы, песи үләне, үги ана яфрагы. |
| | IV | Р.Корбан. «Җәлил турында җыр» | 1. Геройга карата бәяләмә бирү, аның батырлыгына соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү, ло-гик фикер йөртә белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Фикер алышу барышында очраган яңа сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүз запасын баету; матур әдәбият әсәрләре белән танышуны дәвам итү. Сүзлек:дошман, тыл, көрәш, ант, сатмаган, әсир. |
| март | I | Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә ...» | 1. Балаларда туган телебезгә, туган илебезгә, халкыбызның рухи хәзинәләренә мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Матур әдәбият әсәрләре кулланып, сүз байлыкларын арт-ыру, фикер йөртү сәләтен, игътибарлылык һәм хәтердә калу күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә һәм бәйләнешле итеп сөйли белүләренә ирешү, туган телнең матурлыгын һәм аһәңен тоя белергә өйрәтүне дәвам итү. Сүзлек:дәрәҗәле, җитлеккән, камилләшкән, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | затлы. |
| | II | Шигырь уку: Н.Мадьяров. “Көләч яз” | 1. Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белү һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү.<br>2. Балада яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү |
| | III | Шигырь ятлау: Г.Юнусова. «Кара» | 1. Балаларда матур әдәбият аша кошларга карата мәрхәмәтлелек, сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Шигырьне ятлау теләге булдыру, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Шигырьне сәнгатьле укуларына ирешү, шигырьдә еш ишетелгән авазны танып белергә өйрәтү. Сүзлек:сутлы кара туфрак, чем кара. |
| | IV | Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы» | 1. Балаларда китапларга сак караш, хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Сорауларга эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп җавап бирә белү күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтләрен үстерү.<br>3. Шигырь жанрын аера белүне камилләштерү, кыска хикәя төзүләренә ирешү.<br>Сүзлек:китап докторы, дәва, чир. |
| апрель | I | Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Көләч яз» | 1. Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белү һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Шигырьдә балаларга таныш булмаган сүзләрнең, чагыш-тыру алымнарының мәгънәләрен аңлату, сүз байлыгын арттыру һәм сөйләмдә кулланышка кертү.<br>Сүзлек:җиһан, мөлдери, туң, көлтә. |
| | II | Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлем» | 1. Балаларда үсемлекләргә карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү, матур әдәбият аша эстетик тойгылар уяту.<br>2. Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген аңлап, сорауларга дөрес җөмләләр белән җавап бирә белү сәләтен үстерү.<br>3. Бүлмә гөлләрен танып әйтә белү күнекмәләрен камилләштерү; гөлләрне үстерү, карау тәртибе турында белемнәрен ныгыту, кушма сүзләр төзүдә булышлык итү.<br>Сүзлек:Гөлназия, Гөлчирә, Гөлсирин, Гөләндәм, Гөлдәния. |
| | III | Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!» | 1. Әдәби әсәрләрдән кызыклы сюжетлар кулланып, балалар-да юмор хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен,<br>җитезлекләрен үстерү.<br>3. Балаларның галәм турындагы белемнәрен системалаштыру, диалогик сөйләм формаларын камилләштерү, оригами ысулы белән уенчык ясарга өйрәтү.<br>Сүзлек:сер, метеорит яңгыры |
| | IV | Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый» | 1. Матур әдәбият аша балаларда тырышлык, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү.<br>2. Балаларның әдәби әсәрләрне тыңлый һәм аңлый белү сәләтен, эчтәлеге буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сорауларга тулы җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның Г.Тукай иҗаты турындагы белемнәрен баету һәм камилләштерү.<br>Сүзлек:заман, сабыр, ихлас, дәрт. |
| май | I | Хикәянең эчтәлеген сөйләү.<br>Л.Кассиль «Күңелләрдә мәңге сакланыр» | 1. Балаларда Ватанга мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү.<br>2. Хикәянең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл, һәркем ише-терлек һәм аңларлык итеп, грамматик яктан дөрес җөмләләр белән җавап бирү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Бирелгән хикәя аша сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турындагы белемнәрен киңәйтү.<br>Сүзлек: Кремль стенасы, гранит йолдыз, мәңгелек ут, ант, Ватанга тугрылык, пионер. |
| | II | Хикәянең эчтәлеген сөйләү:<br>Р.Төхвәтуллин.<br>«Шомырт нигә елый?» | 1. Әдәби әсәрләр аша балаларда табигатькә сак караш, миһербанлылык, игътибарлылык тәрбияләү.<br>2. Балаларның монологик сөйләмен, фикерне бер юнәлешкә җыя белү сәләтен, хәтерне үстерү.<br>3. Әдәби жанрны аера белү күнекмәләрен, әсәрнең эчтәлеген башкаларга җиткерә белүне камилләштерү. Сүзлек: канат-ботак, әрнү, рәхимсез. Җиһазлар:шомырт агачы рәсеме, туп |
| | III | Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас» | 1. Матур әдәбият аша балаларда көндәлек хәрәкәт эшчәнлегенә ихтыяҗ формалаштыруны дәвам итү, спорт белән шөгыльләнү теләге тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтер сәләтен, бер-берсен тыңлый белүләрен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Шигырь аша кеше тормышында спортның әһәмияте ту-рындагы белемнәрен камилләштерү. Сүзлек:җиләс. |
| | IV | Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә» | 1. Балаларда башкаларны игътибар белән тыңлый белү сый-фаты тәрбияләү.<br>2. Баларның хәтерен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның шигырь эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү, укырга теләк уяту. Сүзлек:тормышка юл. |

**Сөйләм телен үстерү һәм грамотага өйрәтү**

Балада туган теленә карата кызыксыну уяту. Уен ситуацияләре, мәгълүмати-аралашу технологияләре куллану, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, аралашу, нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен) оештыру аша сөйләмне аңлау һәм туган телдә сөйләшәсе килү теләге уяту.

Туган телендә аралашуны үзләштерү өчен шартлар булдыру.

Авазларны дөрес әйтү, сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру.

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | [а] һәм [ә] авазларын өйрәнү. | 1. авзларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү.<br>2.авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә әйтергә өйрәтү.<br>3.образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [У] һәм [Ү] авазларын өйрәнү | 1. авазларны сүзләрдә, сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү.<br>2.авазларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирүне дәвам итү.<br>3. авазларны төрле темпта (акрын, уртача, тиз) әйтергә күнектерү; авазларны сүзләрдә һәм сөйләмдә куллану күнекмәләре бирү; игътибарлылык тәрбияләү.ирешү. |
| | III | [У] һәм [Ү] авазларын өйрәнүне дәвам итү. | 1. авазларны сүзләрдә, сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү.<br>2.авазларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирүне дәвам итү.<br>3. авазларны төрле темпта (акрын, уртача, тиз) әйтергә күнектерү; авазларны сүзләрдә һәм сөйләмдә куллану күнекмәләре бирү; игътибарлылык тәрбияләү.ирешү. |
| | IV | [И] һәм [Ы] авазларын өйрәнү. | 1. авазларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү.<br>2. авазларны аерым-аерым һәм сүзләрдә дөрес әйтү күнекмәләре бирү.<br>3. фонематик ишетү сәләте һәм игътибарлылык тәрбияләү. |
| октябрь | I | [И] һәм [Ы] авазларын өйрәнүне дәвам итү | 1. авазларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү.<br>2. авазларны аерым-аерым һәм сүзләрдә дөрес әйтү күнекмәләре бирү.<br>3. фонематик ишетү сәләте һәм игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [о] һәм [ө] авазларын өйрәнү. | 1. авзларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазларны аерым –аерым һәм сөйләмдә дөрес әйтергә өйрәтү, дөрес сулыш алуны камилләштерү;<br>2.тавыш көчен югары, уртача, түбән дәрәҗәләрдә үзгәртү күнекмәләре бирү;<br>3. фонематик ишетү сәләтен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [о] һәм [ө] авазларын өйрәнүне дәвам итү | 1. авзларны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазларны аерым –аерым һәм сөйләмдә дөрес әйтергә өйрәтү, дөрес сулыш алуны камилләштерү;<br>2. тавыш көчен югары, уртача, түбән дәрәҗәләрдә үзгәртү күнекмәләре бирү;<br>3. фонематик ишетү сәләтен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [Э (е) ] авазын өйрәнү | 1. [ э (е)] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым – аерым һәм сөйләмдә дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2. темп һәм интоеация өстендә эшләү;<br>3. фонематик ишетү сәләтен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ноябрь | I | [Э (е) ] авазын өйрәнүне дәвам итү | 1. [ э (е)] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым – аерым һәм сөйләмдә дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2. темп  һәм интоеация өстендә эшләү;<br>3. фонематик ишетү сәләтен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [б] авазын өйрәнү | [ б ] авазын аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; сулышны тоткарлау һәм кинәт чыгару күнекмәләре бирү; фонематик ишетү, образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [п] авазын өйрәнү. | 1.[п] авазынаерым килше һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2.фонематик ишетү һәм логик фикерләүсәләтен үстерү ;<br>3.игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [м] авазын өйрәнү. | 1.[м] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. фонематик ишетү сәләтен үстерү, логик һәм образлы фикерләүне үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| декабрь | I | [ в ] һәм  [ w] авазларын өйрәнү. | 1. [ в ] һәм  [ w] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [ в ] һәм  [ w] авазларын өйрәнүне дәвам итү | 1. [ в ] һәм  [ w] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [ф] авазын өйрәнү | 1. [ф] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [т] авазын өйрәнү | 1. [т] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. дөрес темп һәм дикция  өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| гыйнва<br>р | I | | |
| | II | [д] авазын өйрәнү | 1. [д] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. дөрес темп һәм дикция өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [н] авазын өйрәнү | 1. [н] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [с] авазын өйрәнү | 1. [с] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. темп, тавыш көче өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| февраль | I | [з] авазын өйрәнү | 1. [з] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [ч] авазын өйрәнү | 1. [ч] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. темп, тавыш көче өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [ж] авазын өйрәнү | 1. [ж] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сөйләм тизлеге өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [ш] авазын өйрәнү | 1. [ш] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. темп, тавыш көче өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| март | I | [щ] авазын өйрәнү | 1. [щ] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сөйләм тизлеге өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [л] авазын өйрәнү | 1. [л] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | [р] авазын өйрәнү | 1. [р] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сөйләм тизлеге өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [ц] авазын өйрәнү | 1. [ц] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү |
| апрель | I | [ж] авазын өйрәнү | 1. [ж] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сөйләм тизлеге өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | II | [й] авазын өйрәнү | 1. [й] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [к] һәм [къ] авазларын өйрәнү. | 1. [к] һәм [къ] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [к] һәм [къ] авазларын өйрәнүне дәвам итү | 1. [к] һәм [къ] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| май | I | [г] һәм [гъ] авазларын өйрәнү. | 1. [г] һәм [гъ] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. темп, дикция өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | [г] һәм [гъ] авазларын өйрәнүне дәвам итү | 1. [г] һәм [гъ] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. темп, дикция өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | III | [х] һәм [һ] авазларын өйрәнү. | 1. [г] һәм [гъ] авазларын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазларны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен үстерү;<br>3. игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | [ң] авазын өйрәнү | 1. [ң] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;<br>2. бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3. сәнгатьле сөйләм һәм дөрес темп өстендә эшләү, игътибарлылык тәрбияләү. |

### 2.3.4. «СӘНГАТИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ»белем бирү өлкәсе

***ИҖАДИ СӘНГАТЬ***

***Аңлатма язуы***

**«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе**

«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны ***һәм***үз- үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә ***һәм белем бирү бурычларын***билгели.

Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү

**Рәсем ясау**

Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Чәчәк-үсемлек мотивларын (кыр, болын, бакча); паль- метт һәм ярымпальметт, лотоссыман, яфраклар һ. б. мотивларны карау. Балаларның игътибарын композиция үзенчәлегенә (симметрик һәм симметрик булмаган), шул ук вакытта төрле чәчәкләр мотивы кулланылган чәчәк бәйләменә юнәлтү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: вертикаль сабакка карата бизәкнең ике ягы да бертөрле булган симметрик чәчәк бәйләмен ясау ысулын күрсәтү.

Декоратив рәсем буенча алган белем һәм күнекмәләрне өс, баш, аяк киемнәрендә (түбәтәй, алъяпкыч, читек һ. б.), көнкүреш әйберләрендә (сөлге, орчык һ. б.) иҗади кулланудагы милли орнамент элементларын төрләндерергә булышу.

Балаларны татар гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча күмәк эшләр башкарырга өйрәтү. Уртак эшнең эчтәлеге буенча уртак фикергә килергә ярдәм итү.

Яңа төсләр (шәмәхә) һәм төсмерләр (куе шәмәхә, аксыл шәмәхә) белән таныштыру. Яңа төсмерләр табу өчен, төсләрне кушарга өйрәтү. Төсләр кушылмасын мөстәкыйль сайларга күнектерү.

Рәсемнәрдә көнкүреш предметларын, татар халык әкиятләре персонажларын чагылдыра белүне камилләштерү. Балаларда Г. Тукай, А. Алиш әкиятләре («Сертотмас үрдәк», «Кем көчле?», «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык») буенча сюжетлы композицияләр иҗат итәргә теләк тудыру.

Туган шәһәр (авыл) тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемдә чагылдыруларын хуплау. Рәсемнәрне балалар белән бергәләп карау һәм ясалган рәсем буенча сөйләргә теләк уяту. Балаларның иҗади активлыклары үсешенә ярдәм итү.

**Әвәләү**

Әвәләүгә карата кызыксыну үстерүне дәвам итү; балчыктан (камыр, пластилиннан) әвәли белүне камилләштерү.

Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларына карап әвәләү, аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белү күнекмәләрен үстерү.

Рельефлы сурәтләү техникасы белән таныштыру. Табигый үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм дөрес пропорцияләр белән, тукранбаш әвәләргә өйрәтү. Әвәләүне плинтустан - нигездән башларга, шуның өстенә махсус пычак очы белән рельефның контурлы рәсемен төшерергә кирәклегенә балаларның игътибарын юнәлтү.

Савыт-сабаны (кувшин, ваза, чүмеч, комган һ. б.) тасма ысулы белән әвәләүне камилләштерү: офбөтен балчык кисәгеннән әвәләү, вак детальләр белән тулыландыру, махсус таякчык, штамп ярдәмендә бизәү.

Балаларның уйлап чыгара белүләрен, катлаулы булмаган сюжет һәм образлар («Сабантуйда», «Көянтәле кыз», «Өч кыз» һ. б.)тудырырга тырышуларын күрә белү һәм хуплау. Әдәби әсәрләр геройларын (Су анасы, Шүрәле, Камыр батыр һ. б.) күзаллап әвәләргә өйрәнү. Балаларның теләкләрен, иҗатка омтылышларын үстерү.

**Кисеп ябыштыру**

Аппликация сәнгатенә карата кызыксынуны үстерү, аның эчтәлеген катлауландыру һәм төрле сурәтләр тудыру мөмкинлекләрен киңәйтү. Кәгазьне гармун кебек бөкләп, милли бизәкнең бертөрле элементларын (гөлҗимеш, күкчәчәк, акчәчәк таҗларын һәм яфракларын һ. б.ны) һәм, кәгазьне урталай бөкләп, симметрик фигуралар (тукранбаш, ярымпальметт, лалә, кыңгырау чәчәкләре һ. б.) кисә белү күнекмәләрен формалаштыру. Чәчәкләр композициядә матур, ачык итеп чыксын өчен, аппликацияне кәгазьләрне ертып төзү техникасын файдалану. Төрле сурәтләү чараларын яраштыра белүләрен хуплау

Георгин (дәлия), пион, астра (кашкарый) чәчәкләреннән композиция төзү өчен, күләмле аппликация ысуллары белән таныштыру. Балаларның композицияне төрле детальләр (кошлар, бал кортлары, күбәләкләр һ. б.) белән тулыландырырга теләүләрен хуплау. Бер бит кәгазьдә төзү һәм ябыштыру ысулы кулланып, төрле билгеләнештәге архитектура корылмаларыннан (цирк, вокзал, супермаркет, өйләр һ. б.) торган сюжетлы аппликацияләр ясарга өйрәтү.

**Сынлы сәнгатькә тарту**

Балаларны сынлы сәнгатькә якынайту һәм аңа карата кызыксыну уяту. Республика сынлы сәнгате эшлеклеләренең (Х. Якупов, И. Зарипов, Р. Шәмсетдинов һ. б.) танылган әсәрләре белән таныштыру. Балаларны «пейзаж» төшенчәсе, Алабуга шәһәрендә туган күренекле рус пейзажчысы И. И. Шишкинның иҗаты («Иртәнге нарат урманы», «Арышлар», «Аланлык» һ. б.) белән таныштыру. Сурәткә карата хис-кичерешләрен чагылдыра белергә, аны аңлап сөйләргә, тормышларында булган вакыйгалар белән чагыштыра белергә өйрәтү.

Сәнгатьнең борынгы төре булган керамика һөнәре белән, хәзерге рәссам-керамикларның (А. Шубин, А. Абзгилдин, Р. Миргалимов, А. Миңнуллина) иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын керамик эшләнмәләрнең милли үзенчәлеге силуэт формасында гына түгел, ә орнамент бизәлешендә дә чагылуга юнәлдерү. Милли орнамент элементларын аера белергә ярдәм итү. Балаларның игътибарын рус милли костюмының үзенчәлекләренә юнәлтү, татар традицион костюмы белән (баш, өс, аяк киемнәре, бизәнү әйберләренең үзенчәлекләре) чагыштыру. Милли киемнәрдә охшаш һәм аермалы якларны табарга булышу.

Балаларны күн мозаикасы сәнгате белән таныштыру. Күн туфли, башмаклар, читекләрне; читекләрнең ал һәм балтыр өлешләрендәге бизәкләрне карау. Бер-берсенә матур туры килеп торган элементларны бөтен бер композициягә җыйган төсле фонга, кәкре сызыклы ябык формаларга, аларны капма- каршы төстәге ефәк җепләр белән тегүгә һ. б. га игътибар итү.

Балаларны туган шәһәр архитектурасы белән таныштыруны дәвам итү. Бинаның конструкциясе аның билгеләнешенә (торак йорт, мәчет, кинотеатр һ. б.) бәйле булганын аңлату!

Бер билгеләнештәге архитектура корылмаларының охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү. Агачны кисеп бизәкләр төшерелгән иске агач өйләр, өй тирәсендәге каралты-куралар (капка, коймалар) сакланып калган Иске Татар бистәсенә (Казанның борынгы бер өлешенә) экскурсия оештыру. Кисеп ясалган бизәкләрнең үзенчәлегенә, аларның пропорция һәм төсләр чишелешенә (татар чигүенә, күн мозаикасына охшашлыкка) игътибаритү. Кремльнең архитектура ансамбле (Спас башнясы, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Преображенск башнясы, Благовещенск соборы һ. б.) белән таныштыру. Тарих һәм культура объектларын аңга алу тәҗрибәсе формалаштыру. Кремль тарихын өйрәнүгә теләк уяту.

Китап иллюстрациясе турындагы белемнәрне ныгыту. Балаларны Р. Миңнуллин, Ш. Галиев, Р. Вәлиева һ. б.ның шигырьләренә образлар тудырган рәссам-иллюстраторларның иҗаты белән таныштыру. Бер үк әдәби әсәргә төрле рәссамнар иҗат иткән иллюстрацияләрне чагыштыра белү, аларны ничек кабул итүләре турында сөйли белү күнекмәләрен үстерү.

***Комплекслы – тематик план***
***Рәсем***

| Ай | Атна | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| сентярь | I | Җәй турында картина | -җәй көнендә алган тәэсирләрен рәсемдә чагылдырырга; төрле агач, куак, чәчәк ясарга;үзенең һәм иптәшләренең рәсемнәрен бәяләргә.<br>-рәсемне битнең билгеле бер өлешенә, яисә бөтен биткә урнаштырырга.<br>-образлы кабул итү, образлы күзаллау;иҗади активлык |
| | II | Декоратив рәсем ясау | -квадратта бизәк төзү(почмак һәм уртасында да),пумаланың очы белән ясау алымын куллану(нокта ясау);<br>-буяу белән ясау.<br>-эстетик кабул итү, симметрия хисе, композиция хисе |
| | III | Алтын көз. | -көз фасылын дөрес пропорциягә китереп ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>-төсләрне дөрес сайлау алым-н ныгыту өстендә эшне дәвам итү.<br>-тирә-як турындагы күзаллаулары турындагы белемнәрен камилләштерү. |
| | IV | Яфраклар б-н рәсем ясау | -рәсемнең эчтәлеген уйлау, рәсем ясауның төрле ысулларын искә төшерү;<br>-үзләренең һәм иптәшләренең рәсемнәренә анализ ясау һәм бәя бирү.<br>-уйланганны ахырына җиткерергә омтылыш, иҗадилыкларын үстерү. |
| | V | Натурадан ясау “Миләш агачы ботагы” | -балаларны натурадан ясауны, миләш агачының үзенчәлеген рәсемдә чагылдыра белүне ныгыту.<br>-акварель белән ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>-образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| октябрь | I | Минем ятаткан уенчыгым | -әкияти образны чагылдырып уенчыклар ясауны һәм сүрәтләү техникасын үстерү.<br>-балаларның фантазияләрен үстерү, рәсемдә әкияти образ тудыру осталыгын ныгыту.<br>-буяулар белән мөстәкыль рәвештә эш итүне өйрәтү. |
| | II | Бүлмә гөлләре | -рәсемдә бүлмә гөленең характерлы үзенчәлекләрен күреп (төзелешен, үсешен, яфрак формасын) чагылдырып ясауны камилләштерү.<br>- башта контурны карандаш белән ясарга.<br>- рәсемне пөхтә итеп буяу күнекмәләрен. |
| | III | Кичке шәһәр | -балаларны сюжетлы рәсем ясарга, рәсемдә төрле зурлыктагы йортларны чагылдырып кичке шәһәр урамын сүрәтләргә өйрәтү.<br>-буяу һәм пумала белән эшләү алымнарын үстерү.<br>-матур ясалган рәсемнәр гә карап шатлану күнекмәләре формалаштыру. |
| | IV | Декоратив рәсем “Бөтеркә” | -балаларны алда өйрәнелгән ясау алымнарын кулланып агач ботагына бөтеркәләр ясарга өйрәтү.<br>-акварель белән ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>-образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын үстерү. |
| ноябрь | I | Балалар бакчасында без ничек уйныйбыз | -рәсемдә тирә-юньне чагылдырып рәсемнең композициясен төзү, кешеләрнең характерлы хәрәкәтләрен чагылдырып ясау осталыгын үстерү.<br>-эстетик кабул итүне, буяу белән ясау алымнарын ныгыту.<br>-үз рәсемнәрен карау, аларны бәяли ала белү формалаштыруны дәвам итү. |
| | II | Син кайсы ел фасылын яратасың | -балаларда ел фасыллрына карата кызыксыну уяту, рәсемнең эчтәлеген чагылдырып ясау алымнарын ныгыту.<br>-сурәтне кәгазь битендә урнаштырырга өйрәтү.<br>-рәсемне ясау һәм карандаш белән буяу алымнарын ныгыту. |
| | III | Т.Д.Мамина-Сибряка “Серая –Шейка” дигән әкияте буенча рәсем ясау. | -ясарга теләгән эпизодны сайлап алып, рәсемдә авторның әсәреннән сюжет сүрәтли белү күнекмәсен камилләштерү.<br>-рәсемдә әкияти образ тудыру осталыгын ныгыту.<br>-буяулар белән мөстәкыль рәвештә эш итүне өйрәтү. |
| | IV | Дымка аты | -халык декоратив бизәкләр мотивы буенча күләмле әйбер бизәргә;бизәкнең төп элементы, аларның урнашуын ачыкларга.<br>-эстетик кабул итүне, буяу белән ясау алымнарын ныгыту.<br>-үз рәсемнәрен карау, аларны бәяли ала белү формалаштыруны дәвам итү. |
| | V | Музыка залында биибез | -балаларны рәсемдә өс киемнәрне төрле төстә, үрнәк буенча ясауны һәм хәрәкәтләрне чагылдыруны ныгыту.<br>-кисточка очы белән нечкә линияләр сызу буенча кабатлау.<br>-төс, ритм, композицияне, хохлома бизәкләрен бирү күнекмәләрен ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| декабрь | I | Натурадан ясау “Бүлмә гөле” | -бүлмә гөленең үзенчәлекле формасын чагылдырып (сабагын, яфракларын, чәчәген) натурадан ясарга өйрәтү.<br>тирә-якны матурлыкка әйләндерү теләге уяту.<br>-коллектив белән эшләүкүнекмәләрен ныгыту. |
| | II | Кышкы пейзаж | -балаларны әйләнә-тирә тормышны чагылдырып, төсмерләрне урынлы кулланып сюжетлы композиция тудырырга өйрәтү.<br>-рәсемне бөтен биткә урнаштырырга өйәтү.<br>-төрле буяулар белән ясау күнекмәләрен эстетик, образлы күзаллауны үстерү. |
| | III | Күңелле кар бабайлар | -балаларны табигый булмаган төртеп ясау алымы белән төрле зурлыктагы кар бабайлар иҗат итәргә өйрәтү.<br>-альбом битенең уртасына рәсемне зур итеп ясарга, рәсемнең тышкы сызымын гади графиткарандаш белән ясауны һәм төсле карандашлар белән буяау алымнарын ныгыту.<br>-эшне ахырына кадәр җиткерү, үз эшеңә бәя бирә белүне үстерү. |
| | IV | Чыршы янында кар кызы | -кар кызы образын ясарга, карандаш белән төрлечә басым ясап буярга өйрәтү.<br>-рәсем ясауның техник күнекмәләрен ныгыту.<br>-үз рәсемнәрен карау, аларны бәяли ала белү формалаштыруны дәвам итү. |
| гыйнвар | II | Бәс белән капланганагачлар | -эстетик күзаллауны үстерү.<br>-табигатьнең матурлыгын рәсемдә сурәтләү күнекмәләрен ныгыту.<br>-гуаш һәм сангина белән ясау күнекмәләренә өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | Декоративрәсем ясау “Чәчәк бәйләме” (салкын тонда) | -балаларны катлаулы ике төсмерне куланып эш итү алымнары белән таныштыру.Пумала белән салмак борылышлар ясауны ныгыту.<br>-пумала белән ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>-бизәкләр белән соклану хисләре тәрбияләү. |
| | IV | Дымка курчагын бизә | -дымка курчагы фигурасын буярга, бизәкне аскы өлеше киңәйгән итәккә дөрес бизәк төшерергә өйрәтү.<br>-иҗадилык, образлы күзаллау күнекмәләрен ныгыту.<br>-төс, ритм, композицияне, хохлома бизәкләрен бирү күнекмәләрен ныгыту. |
| февраль | I<br>II | Хохлома бизәкләре | -дулкынлы линияләр, үләннәр, кыска уралмалар ясарга өйрәтү.<br>-кисточка очы белән нечкә линияләр сызу буенча кабатлау. Буйда җимеш һәм яфракларнытигез итеп урнаштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>-төс, ритм, композицияне, хохлома бизәкләрен бирү күнекмәләрен ныгыту. |
| | | Конек-Горбунок | -балаларның фантазияләрен үстерү,<br>-рәсемдә экияти образ тудыру осталыгын ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | -буяулар белән мөстәкыль рәвештә эш итүне өйрәтү. |
| | III | Сакта торучы солдат | -сугышчы образын, костюмы, позасы, коралының үзенчәлекләрен рәсемдә бирергә өйрәтү.<br>-сурәтне кәгазь битендә урнаштырырга, рәсемне ясау, буяу кунекмәләрен куллану.<br>-Рәсәй армиясенә кызыксыну һәм хөрмәт уяту, зур итеп ясарга өйрәтү. |
| | IV | Әкият патшалыгында | -рәсемдә әкиятнең характерлы билгеләрен бирә, рәсемне дөрес итеп буярга, сангина белән ясарга, сурәтне кәгазь битендә урнаштырырга өйрәнү.<br>-эстетик күзаллауны ныгыту.<br>-мөстәкыйль рәвештә сюжет уйлап табарга күнектерү. |
| март | I | Төркем бүлмәсендә минем яраткан уен почмагым | -иҗат итәргә теләгән сүрәтләрнең, предметларның формаларын дөрес чагылдырып ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>-карандаш белән ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>-мөстәкыйльлек сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | Мальчик с пальчик | -әкиятне сүрәттә бирү күнекмәләрен ныгыту.<br>-күзаллау һәм уйлап табу күнекмәләрен ныгыту.<br>-рәсем ясау күнекмәләрен үстерү. |
| | III | Уйлап рәсем ясау | -күзаллау, иҗадилык һәм уйлап табу күнекмәләрен ныгыту.<br>-үзеңнең эшеңнең эчтәлеген уйлап табарга өйрәтү. Башлаган эшне ахыргача бетерергә өйрәтү.<br>-гади карандаш, төслбе мел белән ясау күнекмәләрен ныгыту. |
| | IV | Кем булырга телисең | -балаларны рәсемдә олылар хезмәте эшчәнлеген, һөнәрен чагылдырган киемнәр белән кешеләр фигурасын ясарга өйрәтү.<br>-хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.<br>-башлаган эшне ахыргача бетерергә өйрәтү. |
| апрель | I | Декоратив рәсем “Бөтеркә бизәк” | -балаларның декоратив иҗатын халык бизәкләре мотивлары буенча бөтеркә бизәкне куланып кәгазь битенә бизәкле композиция иҗат итү күнекмәләрен ныгыту.<br>-күзаллау һәм уйлап табу күнекмәләрен ныгыту.<br>-рәсем ясау күнекмәләрен үстерү. |
| | II | Декоратив рәсем ”Чәчәк композициясе белән кошны бизәү» | - дымка сәнгате буенча ясалган уенчыкны буярга өйрәтү.<br>-эстетик күзаллауны, ритмны, корылышны, төсне тою күнекмәләрен - иҗадилыкны ныгыту.<br>-халык сәнгатенә хөрмәт, уңай эмоциональ чагылыш тәрбияләү. |
| | III | Өмә | -рәсемдә кеше хезмәтен чагылдыру.<br>-хәрәкәт вакытында кеше образын бирүне ныгыту.<br>-образга төрле эчтәлек бирергә өйрәтү. Карандаш белән рәсем ясарга, буяганда карандашны төрле көч белән басып буярга өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | Китап тышлыгы | -күз күремен яхшырту, карандаш белән беренче форма бирергә күнектерү.<br>-иҗат итергә теләгән сүрәтнең матурлыгын аның формасын дөрес чагылдыра, урнаштыра белүне үстерү.<br>-иҗадилык тәрбияләү. |
| май | I | Безнең шәһәрдә 1нче май бәйрәме | -рәсемдә бәйрәм хисләрен бирә белергә өйрәтү.<br>-аста өйләр, Кремль башнясы, өстә салют белән рәсем композициясен бирү;<br>-эстетик күзаллауны, ритмны, корылышны, төсне тою күнекмәләрен ныгыту; туган ил белән горурлану хисе тәрбияләү. |
| | II | Вазада язгы чәчәкләр | -характерлы үзенчәлекләрен биреп вазада язгы чәчәкләрне сүрәтләү.<br>-ике төсмерне эченә алган табигый төсләр барлыкка китереп ясауны ныгыту.<br>-иҗадилык тәрбияләү. |
| | III | Яз | -характерлы үзенчәлекләрен биреп, табигатьне сүрәтләү күнекмәләрен тәрбияләү.<br>-рәсемне бөтен биткә урнаштырырга өйәтү.<br>-төрле буяулар белән ясау күнекмәләрен эстетик, образлы күзаллауны үстерү. |
| | IV | Туган илем | -мөстәкыйль рәвештә ясарга теләгән рәсемеңнең эчтәлеген уйлап ахырына җиткерә алуларына ирешү.<br>-үз рәсемеңне карап, чагыштыырып бәяли белү күнекмәләрен ныгыту.<br>-рәсем ясау күнекмәләрен үстерү. |
| | V | Безнең шәһәр машиналары | -төрле машиналарны ясарга өйрәтү.<br>-турыпочмаклык формасындагы предметларны һәм аларның өлешләре пропорцияләрен, машиналарның характерлы үзенчәлекләрен ясауны ныгьггу.<br>-рәсемнәрне карандаш белән ясау һәм буяу күнекмәләрен ныгьггу. |

***Комплекслы – тематик план***
***Әвәләү***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| сентябрь | II | “Кибет” уены өчен үзең теләгән җимеш яки яшелчә әвәләү. | -яшелчәләрнең төрле формасын әвәләүдә күрсәтә алуларын ныгыту.<br>-яшелчә-җимеш формаларын геометрик формалар белән туры килүен, аермасын һәм охшашлыкларын табырга өйрәтү.<br>-әвәләүдә тәгәрәтү, сылау, чеметү, алымнарын кулланып һәр яшелчәгә хас булган характерлы үзенчәлекләрен күрсәтергә күнектерү. |
| | IV | Корзинада гөмбәләр | -төп формадан аерылганын күрү күнемәләрен үстерү.<br>-кул һәм бармаклар хәрәкәтен кулланып, предметлар яисә аларның түгәрәк овал, диск формасындагы өлешләрен әвәләү күнекмәләрен ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | -гөмбәләргә хас булган характерлы үзенчәлекләрен күрсәтергә өйрәтү: батыру, эшләпә кырыйларының аска бөйкләнеп торуын, аякларының аска таба юанаюын. |
| октябрь | II | Кыз туп белән уйный | -төрле формасын әвәләүдә күрсәтә алуларын ныгыту.<br>-формаларын геометрик формалар белән туры килүен, аермасын һәм охшашлыкларын табарга өйрәтү.<br>-әвәләүдә тәгәрәтү, сылау,чеметү, алымнарын кулланып һәр яшелчәгә хас булган характерлы үзенчәлекләрен күрсәтергә күнектерү. |
| | IV | Күмәк эш<br>Әтәч гаиләсе белән | -күмәк ижат итү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.<br>-кем эшнең нинди өлешләрен эшләүне килешеп эшләргә омтылыш тәрбияләү.<br>-төрле формасын әвәләүдә күрсәтә алуларын ныгыту. |
| ноябрь | II | Хәрәкәт итүче кеше кеше фигурасы | -үзләштергән төрле ысулларны кулланып, кешенең характерлы хәрәкәтен күрсәтеп әвәләүне камилләштерү.<br>-әвәләүдә тәгәрәтү,сылау,чеметү, алымнарын кулланып һәр яшелчәгә хас булган характерлы үзенчәлекләрен күрсәтергәкүнектерү.<br>-төп формадан аерылганын күрү күнемәләрен үстерү. |
| | IV | Дымка уенчыгы “Алпавыт кызы” | -дымковка уенчыклары мотивы буенча сүрәт тудырырга өйрәтү.<br>-аерым өлеш формасын тартып чыгару алымы аша бер бөтен балчык кисәгеннән фигура әвәләргә күнектерү.<br>-халык декоротив иҗадына хөрмәт тәрбияләү. |
| декабрь | II | Дымка уенчыгы “Кош” | -тулы бер кисәктән сузып, чеметеп ясау алымнарын кулланып кош ясарга өйрәтү.<br>-аерым өлеш формасын тартып чыгару алымы аша бер бөтен балчык кисәгеннән фигура әвәләргә күнектерү.<br>-халык декоротив иҗадына хөрмәт тәрбияләү. |
| | IV | Биюче кыз | -кеше фигурасын гәүдә өлешләрендә кием формасын биреп, пропорцияләрне саклап әвәли өйрәтү.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту.<br>-төп формадан аерылганын күрү күнемәләрен үстерү. |
| январь | II | Чаңгыда шуучы малай | -кеше фигурасының хәрәкәтен чагылдырып әвәләү эшчәнлеген ныгыту.<br>-пропорцияне саклап, кисәкләрне дөрес урнаштыру.<br>-өйрәнелгән алымнарны кулланып эшләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| | IV | Кыш көнендә без ничек уйныйбыз | -кеше фигурасының хәрәкәт эшчәнлеген чагылдырып әвәләүне өйрәтүне дәвам итү.<br>-әвәләгән әйбергә өстәмә предметлар беркетүне ныгыту.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| февраль | II | Минем яраткан хайваным | -яраткан хайваныңны сүрәтли һәм аның характерлы билгеләрен бирә белергә өйрәнү.<br>-әвәләү күнекмәләрен: ике уч арасында әйләндерү, тарту, өлешләрне кысу, кул белән сыпыруны ныгыту.<br>-кайгыртучанлык, хөрмәт тәрбияләү. |
| | IV | Конек-Горбунок | -әкияти образ тудыру,төрле әвәләү алымнары кулланып мөстәкыйль рәвештә эшнең эчтәлеген уйлап әвәләргә өйрәтү.<br>-әвәләгән әйберне эчтәлеккә туры килгән әйберләр белән тулылындыру теләге уяту.<br>-халык декоротив иҗадына хөрмәт тәрбияләү. |
| март | II | Кувшин | -зур кисәк балчыктан лента төзеп кувшин әвәли өйрәнү.<br>-әниләргә кайгыртучанлык, хөрмәт тәрбияләү.<br>-әвәләү күнекмәләрен ныгыту. |
| | IV | Җимлектәге кошлар | -кошларны әвәләргә өйрәнү.<br>-төрле зурлыкта сүрәтләү, койрык, канат, башларын дөрес ураштыру.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |
| апрель | II | Җылы якта яшәүче хайваннар | -хайваннарның характерлы хәрәкәтләрен биреп сәнгать образлары барлыкка китерү.<br>-өрле хәрәкәттә сүрәтләү, койрык, канат, башларын дөрес ураштыру.<br>-лек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |
| | IV | Хайваннар фермасында<br>Күмәк эше | -йорт хайваннарына хас үзенчәлекләрен, торышын биреп әвәләргә өйрәтү.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту.<br>-коллектив композицияләр тудырырга өйрәтү. |
| май | II | Әкият хайваннары | -төрле әкият хайваннарын (Чебурашка, Винни-Пух, мартышка, слоненок) әвәләргә өйрәтү.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру, өлешләрдән ясау, бөтен кисәктән ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>-иҗатка хөрмәт тәрбияләү. |
| | IV | Доктор Айболит һәм аның дуслары | -әкият геройлары образларын ясарга, үз эшеңне һәм иптәшләреңнең эшен бәяләргә өйрәтү.<br>-кеше һәм хайваннар фигурасын күрсәтү, характерлы билгеләрен күрсәтү күнекмәләрен ныгыту.<br>-элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |

***Комплекслы – тематик план***

***Кисеп ябыштыру***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябр | I | Көзге палас | -почмакларын түгәрәкләтеп кисеп, квадрат һәмтурыпочмактан овал һәм түгәрәк формасындагы предметлар кисәалуларын өйрәтү.<br>-ике кул хәрәкәте координациясен **ү**стерү.<br>-эшләрен пөхтә итеп ябыштыра алуларын ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Поезд белән гөмбәгә барабыз | -образлы күзаллауларын үстерү.<br>-предмет һәм аның овал, түгәрәк формасындагы өлешләренкисә алуларын ныгыту.<br>-өчпочмак, турыпочмакларның почмакларын түгәрәклэтепкисүдәкүнектерү. |
| октябрь | I | Яшелчә һәм җимешләр белән тәлинкә | -түгәрәк һәм овал формасындагы предметларны кисү алымнарын ныгытуны дәвам итү.<br>-кайчы белән предметларның характерлы үзенчәлекләрен күрсәтү өчен күз күреме буенча зур булмаган уемтык эшләргә өйрәтү.<br>-пөхтә ябыштыру алымнарын ныгыту. |
| | III | Безнең яраткан аюыбыз һәм аның дуслары | -якынча зурлыгын һәм формасын дөрес чагылдырып, өлешләрдән яраткан уенчык сүрәте тудырырга өйрәтү.<br>-түгәрәк һәм овал формасындагы өлешләрен кисә, сүрәтне пөхтә ябыштыру кәгазь битендә матур итеп урнаштыра алуларын ныгыту.<br>-композиция хисенүстерү. |
| ноябрь | I | Аквариумда балыклар | -төрле төстәге кәгазь геметрик фигуралардан балык силуэтлары кисү үзенчәлекләрен ныгыту.<br>-өлешләп зур һәм кечкенә балыклар кисергә, катлаулы булмаган матур композиция төзергә өйрәтү.<br>-кәгазь буйларын бармакларның вак хәрәкәте белән өзгәләргә күнектерү. |
| | III | Машиналар урамнан баралар | -төрле машиналарның формасын һәм өлешләренең үзара урнашуын чагылдырырга өйрәтү.<br>-түгәрәк буенча, турыга кисүнең күптөрле алымнарын; пөхтә ябыштыру алымын ныгыту.<br>-образлы уйлау, уйлап чыгаруларын үстерү. |
| декабрь | I | Куркак куян | -балаларга кәгазне гармон сыман бөкләп тигез кисәкләр барлыкка китереп кисү алымын өйрәтү.<br>-кисү һәм төгәл ябыштыру ысулларын ныгыту.<br>-образлы күзаллау күнекмәләрен үстерү. |
| | III | Яңа ел белән котлау открыткасы | -бәйрәм тематикасына туры килгән сурәт белән бәйрәм открыткасы ясый өйрәнү.<br>-кәгазьне берничә өлешкә бөкләп тигез өлешләр, ике өлешкә бөкләп симметрик фигуралар кисә өйрәнүне дәвам итү.<br>-кисү һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту. |
| январь | I | Күмәк эш<br>“Суда йөзүче пароход” | -балаларда күмәк эшчәнлеккә кызыксыну уяту.<br>-коллектив композициянең өлешләрен тудыру, эш алымнарын һәм пөхтә эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>-эстетик кабул итү, образлы күзаллау күнекмәләрен үстерү. |
| | III | Балалар теләге буенча | -балаларда кузаллау, иҗадилык, уйлап табу һәмтөсне кабул итү, композиция хисе, барлыкка килгән сүрәтне карау һәм бәяли белүне үчтерү.<br>-төрле төсләрне сайлауны кабатлау.<br>-кисү һәм төгәл ябыштыру ысулларын ныгыту. |
| ф | I | Матрос сигнал флаглары | -кешене сурәтли, костюм өлешләрен, кул, аягын, башын кисә өйрәнү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | белән | -кешенең гади хәрәкәтләрен сурәтли өйрәнү.<br>-симметрик өлешләрне икегә бөкләп кисү, кәгазьдә матур итеп урнапггыру күнекмәләрен ныгыту. |
| | III | Пароход | -элек өйрәнгәннәрне турыпочмаклыкның почмакларын кисү, пароходның башка өлешләрен, төрле формадагы өлешләрне кисеп образлы картина ясарга өйрәтү.<br>-гармун кебек бөкләп, бертөрле өлешләрне кисү күнекмәләрен ныгыту.<br>-кәгазьдә матур итеп урнаштыру күнекмәләрен ныгыгу. |
| март | I | Шәһәребезнең яңа йортлары | -төрле формадагы өлешләрне кисү, икегә бөкләп симметрик өлешләрне кисү күнекмәләрен ныгыту.<br>-күзаллау, иҗадилык һәм уйлап табу күнекмәләрен үстерү, матур эшләрне табарга, эше турында сөйләү сәләтен үстерү.<br>-композицияне башка туры килгән предметлар, детальләр белән баету теләге тудыру. |
| | III | Кис һәм үзең теләгән уенчыкны ябыштыр | -ябыштыру өчен кыен булмаган сюжет уйлаарга. кызыклы, эчтәлеклеэш сайларга өйрәтү.<br>-кисү һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>-активлык, иҗадилык, мөстәкыйльлек сыйфатларын тәрбияләү. |
| апрель | I | Айга очу | -ябыштырганда ракета образын бирергә, пропорцияләрне дөрес сайларга өйрәтү.<br>-икегә бөкләп күлмәк кисәргә өйрәтү.<br>-төгәл итеп кисү, ябыштыру өстендә эшләү |
| | III | Җиңү бәйрәменә әти-әниләргә чакыру кәгазе эшләү. | -кайчы белән эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>-төсләрне дөрес сайларга өйрәтү.<br>-төп өлешне турыпочмаклык формасын кисү, түгәрәкләп почмакларны кисеп алу, берничә өлешкә бөкләп тигез формалар кисү өстендә эшләү. |
| май | I | Ямьле яз | -коллектив композициянең өлешләрен тудыру күнекмәләрен ныгыту.<br>-квадрат һәм буйлы кәгазьдә рәсемнәрне симметрик рәвештә урнаштыру, төрлечә кисү күнекмәләрен ныгыту.<br>-төгәл итеп кисү, ябыштыру өстендә эшләү. |
| | III | Кошлар | -образлы күзаллауны иҗадилыкны устерү.<br>-төрле геометрик фигурадан туры итеп, диагональ буенча кисеп төрле әйберләрне сурәтләрен ясау буенча эшләү.<br>-төгәл итеп кисү, ябыштыру өстендә эшләү. |

### *Җыр*

### *Аңлатма язуы*

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында катнаш музыкаль эшчәнлек үткәрү.

### 2.3.5. «ФИЗИК ҮСЕШ»белем бирү өлкәсе

***Сәламәтлек***

***Аңлатма язуы***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк- җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка

балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

### *ФИЗИК КУЛЬТУРА*

### *Аңлатма язуы*

«Физик культура» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда физик культурага кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү. Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү. Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету. Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен вариантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.

### *САФ ҺАВАДА ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР*

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

### *Комплекслы-тематик план*

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында»<br>«Бүре һәм куяннар»<br>«Чыпчыклар һәм мәче» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль»<br>«Козгын һәм чебиле тавык» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай»<br>«Коткаручы таяк» | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | «Җитез бул»<br>“Көтүче һәм көтү” | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычканнар», | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Октябрь | I | “Ябалак”<br>“Куыш уены” | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |
| | | “Төсле автомобильләр” | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | «Кыршау эченә ыргыт» | Дус – тату уйнауны булдыру, туп ыгргыту, төгәллек сыйфатлары тәрбияләү |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |
| | III | «Бау аша сикер», «Куянкай» | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | IV | «Почмак алыш» «Әби, уян!» | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” “Атлар һәм колыннар” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” “Ялкау мәче” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | «Төлке һәм тавыклар», | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| | | “Үз төсеңне тап” “Туп кайда” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | «Мин качам, син тот», “Күбәләк тоту” | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру**,** сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | “Казлар - аккошлар” “Ялкау мәче” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | «Кемдә йөзек?» | Халык уеннарына карата кызыксыну уяту, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | II | “Кем беренче?” “Почмак алышу” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | «Куяннар һәм төлке» “Нәрсә оча” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Кегляны аудар”<br>“Чүлмәк вату” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | «Балалар һәм этәч» | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру**.** |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| январь | I | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Аксак төлке” | Бер аякта сикерү кәнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | IV | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | III | «Ак, димә, кара, димә» | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | IV | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| март | I | «Парлы эстафета» | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | «Тупны ыргыт» | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | III | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, житезлекләрен үстерү. |
| | | «Кармак» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | IV | «Буяучы һәм буяулар», | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| апрель | I | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | II | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Челән белән бакалар” | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | III | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Житезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | IV | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| май | I | «Идәндә калма», | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | II | “Тупны, сикертеп, алып бар” | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | | “Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | “Буш урын” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | IV | «Кем тизрәк?» | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |

### *2.4 ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ*

| **Ай** | **Тема** |
|---|---|
| сентябрь | 1. Консультацияләр: “Һәр балада талант бар”, “Балага спорт төре сайлыйбыз”, “Гаилә конфликты һәм балалар”, “Төзү буенча балаларга уеннар”, “Кичке укуның файдасы”.<br>2. Ата–аналар җыелышы:<br>- 6-7 яшьлек балаларның психо-физик үсеш үзенчәлекләре<br>- «Юлларда куркынычсызлык»<br>- «Малайлар, кызлар-ике төрле дөнья»<br>- «УМК».<br>3. Табиб киңәшләре: “Ваксинопрофилактика”, “Компьютерның һәм телевизорның зыяны”, “Күзләр өчен гимнастика”.<br>4. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| октябрь | 1. Консультацияләр: “Хәрәкәтле уеннарның бала организмы өчен файдасы”, “Бишек җырлары җырлыйбыз”, “Яссытабанлылыкны кисәтү”, “Ни өчен бала уенчыкларны җыярга теләми?”, “Сәләтле бала”.<br>2. Газета “Өлкәннәрне тәбриклибез һәм бәйрәм белән котлыйбыз!”<br>3. Өлкәннәрне бәйрәм белән котлау, балаларның үз куллары белән ясаган бүләкләрен бирү.<br>4. “Сөмбелә” бәйрәмен уздыру.<br>5. Табиб киңәшләре: “Бабасыр”, “Балаланың гаиләдәге физик тәрбиясе”<br>6. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| ноябрь | 1. Консультацияләр: “Профилактик прививкалар”, “Музыкотерапия”, “ Балалар өчен төзү уеннары”.<br>2. Газета “Бәйрәм белән, кадерле әниләр!”<br>3. Табиб киңәшләре: “Салкын һава турында 5 төрле әти – әниләрнең күзаллаулары”, “Матур һәм сәламәт тешләр”, “Төркемгә чир керсә...”<br>4. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>5. Белешмәлек “Бала белән бергә уйныйбыз”. |
| декабрь | 1.Консультацияләр: “Саф һавада йөрүнең файдасы”, “Сюжетлы-рольле уеннар аша балаларда туган телне үстерү”, “Өйгә уйный-уйный кайтабыз”.<br>2. Балалар өчен шугалак (тау) төзү.<br>3. Газета “Тәҗрибәләр үткәрәбез”, “Хуш киләсең, Яңа ел”. |

| | |
|---|---|
| | 4. “Хуш киләсең, Яңа ел!” бәйрәме уздыру.<br>5. Табиб киңәшләре: “Салкын тиюдән саклану чаралары”, “Гәүдә төзелеше бозылуы”, “Саф һавада хәрәкәтле уеннар”.<br>6. “Сюжетлы-рольле уеннар” күргәзмәсенә әзерлек һәм үткәрү.<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>8. Ата–аналар җыелышы: “Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән тәҗрибә-тикшерү эшчәнлеге” |
| январь | 1.Консультацияләр : “Бармак уеннары”, “Юл һәм балалар”.<br>2. Газета “Чыныктыру чаралары”.<br>3. Мастер –класс “Сәламәт булыйк: чыныктыруалымнары”.<br>4. Рәсем конкурсы “Айболит киңәшләре”.<br>5. Табиб киңәшләре: “Грипкка каршы аромотерапия”, “Туберкулездан саклану”, “Яссытабанлылык булса, нишләргә?”<br>6. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| февраль | 1. Консультацияләр: “Ишетергә һәм тыңларга өйрәнәбез”. “Биибез дә, җырлыйбыз”,”Ни өчен балаларга төзү уеннары кирәк”<br>2. Газета “Бәйрәм белән әтием, абыем, бабам”.<br>3. “Ватанны саклаучылар көне”  бәйрәмен уздыру.<br>4. Табиб киңәшләре:“Отморожение», “Бала йокысы”, “Йокыдан уяну гимнастикасы”.<br>5. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| март | 1. Консультацияләр: “Тиктормас балаларга уеннар”, “Начар сүзлелек”, “Балаларның урамда уйнау җирлекләре”.<br>2.  Рәсем конкурсы “Минем яраткан әкият героем”.<br>3. “8 март – халыкара хатын кызлар көне” бәйрәме уздыру.<br>4. Табип киңәшләре: “Җил чәчәге авыруы”, “Авитаминоз”.<br>5. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| апрель | 1. Консультацияләр:«Витаминотерапия”, “Балалар алдыйлар”, “Беренче китаплар”.<br>2. Газета “Көлке көне”, “Космонавтика көне”, “Бөек татар шагыйре Г.Тукай”.<br>3. Табиб киңәшләре: “Тычканнар таратучы чирләр”, “Саф һавада йөрү бик файдалы”.<br>4. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| май | 1. Консультацияләр: “Кояш, су һәм һава безнең дуслар”, “Музыкаль аптека”, “Балаларның җәйге ялы”, “Су белән уеннар”, ”Комлыкта төзү уеннары”<br>2. Газета “Без сезне мәңге онытмабыз!”<br>3. Рәсем конкурсы “Җиңү көне белән!”<br>4. Табиб киңәшләре: “Талпан авыруы”, “Баланың күзләрен саклыйк”<br>5. Әти–әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Ата–аналар җыелышы: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту”. |

## 3. Оештыру бүлеге.
### 3.1. Балаларның көндәлек тормышын һәм эшчәнлеген тасвирлау.

Балалар бакчасында белем бирү эшчәнлеге атнага биш көн тәртибендә үткәрелә. Балалар бакчасында булу вакыты: $6^{00}$ сәгатьтән $18^{00}$ сәгатькә кадәр.

Укыту эшчәнлеге 1 нче сентябрьдән 31 нче майга кадәр. Җәйге сәламәтләндерү вакыты: 1 нче июньнән 31 нче августка кадәр.

Көн тәртибе балаларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә һәм гармонияле үсешенә булыша. Көн тәртибен төзегәндә һәм оештырганда мөһим кабатланучы компонентлар искә алынды:

- ашау вакыты;
- көндезге йокы;
- саф һавада,бинада булу дәвамлыгы.

Төркемдә **көндәлек режим** балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп төзелгән.

| Вакыты | Эшчәнлек | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6.00-8.10 | Балаларны кабул итү. Саф һавада булу. Мөстәкыйль һәм бердәм уен чәнлеге. | | | | |
| 8.10-8.20 | Иртәнге гимнастика. | | | | |
| 8.20-8.30 | Бердәм эшчәнлек. Иртәнге ашка әзерлек. | | | | |
| 8.30-8.50 | Иртәнге аш. | | | | |
| 8.50-9.00 | Мөстәкыйль уен эшчәнлеге. ББЭнә әзерлек. | | | | |
| 9.00-10.50 | Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге | | | | |
| | дүшәмбе | сишәмбе | чәршәмбе | пәнҗешәмбе | җомга |
| | 1. 9.00-9.30<br>2-3. 9.50-10.15<br>10.25-10.50 | 1. 8.50-9.20<br>2. 9.30-10.00<br>3. 10.10-10.40 | 1. 8.50-9.20<br>2. 9.30-10.00<br>3. 10.10-10.40 | 1. 8.50-9.20<br>2. 9.30-10.00<br>3.10.10-10.40 | 1. 9.15-9.45<br>2.10.00-10.25<br>10.35-11.00<br>3. физ-ра с.һ.<br>11.25-11.55 |
| 9.55-10.05 | Икенче иртәнге аш (эшчәнлекләр арасында) | | | | |
| | 10.05 | 10.05 | 10.05 | 10.20 | 9.55 |
| 10.40-10.55 | Урамга чыгарга әзерлек. | | | | |
| 10.55-12.00 | Саф һавада булу | | | | |
| | дүшәмбе | сишәмбе | чәршәмбе | пәнҗешәмбе | җомга |
| | 11.00-12.00 | 10.50-12.00 | 10.55-12.00 | 10.50-12.00 | 11.10-12.00 |
| 12.00-12.10 | Урамнан керү. Балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге. | | | | |
| 12.10-12.20 | Бердәм эшчәнлек. Көндезге ашка әзерлек. | | | | |
| 12.20-12.50 | Көндезге аш. | | | | |
| 12.50-15.00 | Йокыга әзерлек. Көндезге йокы. | | | | |
| 15.00-15.10 | Йокыдан уяту. Йокыдан соңгы гимнастика, чыныктыру процедуралары. | | | | |
| 15.10-15.30 | Кече ашка әзерлек. Кече аш. | | | | |
| 15.30-16.30 | Мөстәкыйль уен эшчәнлеге. Белем бирү эшчәнлеге.Балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге.Түгәрәкләр (ярты төркем). | | | | |
| | | | | | |
| 16.30-16.40 | Бердәм эшчәнлек. Кичке ашка әзерлек. | | | | |
| 16.40-17.00 | Кичке аш. | | | | |
| 17.00-17.10 | Кичке саф һавага чыгарга әзерлек. | | | | |
| 17.00-18.00 | Саф һавада булу. Балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге.<br>Ата-аналар белән әңгәмә. | | | | |

### 3.2. Методик программалар белән тәэмин ителеш

**Әдәбият**

**Төп программалар:**

1. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә», Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А. редакциясендә.
2. 49 нчы "Гөлназ" балалар бакчасының төп белем бирү программасы.

**Парциаль программа:**

«Сөенеч-Радость познания» региональная программа дошкольного образования.

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы / Р.К. Шаехова - Казань, РИЦ, 2016

**Кулланыла торган әдәбият:**


1. Туган телдә сөйләшәбез: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буеча методик ярдәмлек / Төз.: З.М.Зарипва Л.Н.Вәҗиева, Р.С.Зөфәрова һ.б.- Казан: ФОЛИАНТ, 2012.- 304 с.
2. Закирова К.В. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.-424 б.
3. Закирова К.В. "Әхлак нигезе-матур гадәт" (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова.- Казан:Мәгариф,2004.-383б.
4. Закирова К.В., Мортазина Л.Р.Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак: методик кулланма.- Казан: Редакционно-издательский центр,2012
5. Иң матур сүз: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хресоматия. – Казан: Мәгарф, 2000.- 335 б.
6. Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах. Редакторы: М.И.Чернова, И.Р.Саганов. Казань, 208 – 323 с.
